ШӘМСИЯ
ҖИҺАНГИРОВА

# Җирсә



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2001

ББК 84(2Рос=Тат)−5
Җ61

**Җиһангирова Шәмсия**

Җ61 Җирсү: Шигырьләр, һырлар.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.—191 бит.

Шагыйрәнең яңа китабына лирик-фәлсәфи шигырьләре, һырлары тупланды.

ISBN 5-298-01042-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2001

# Кояш нуры тамган җырлар

Мин аны күптәннән, бик күптәннән беләм инде. Үзем әтисез-әнисез үскәнгәме, мин Казанның ул чакларда бердәнбер татар мәктәбендә — нигездә, ятим балалар укыган 10 нчы интернат-мәктәптә аеруча еш булырга, сабыйларның моңсу күз карашларыннан, үз-үзләрен үтә тәртипле тотышларыннан ниндидер әчке мәгънә эзләргә, һәм шуның белән хисчән күңелемә бер юаныч табарга тырыша идем. Очрашуларның берсендә игътибарымны кыюсыз гына, чандыр гына бер кызый җәлеп итте. Ул сәхнәгә тыйнак кына чыгып, халкыбызның бер озын көен җырлады. Гөрләтеп кул чаптык — тавышы челтерәп аккан чишмәдәй саф, күңелләрне әсир итәрлек иде. Аннан шул ук кыз, кабат чыгып, үз шигырьләрен укыды. Алары да ихлас һәм самими иде. Исем-фамилиясе Шәмсия Гарипова икән. «Бик матур исем куйганнар икән бу чибәр кызга,— диештек,— кояш мәгънәсендә». Зур үсеп, тормыш юлларын байтак кичкәч, аның фамилиясе Җиһангировага алышынды — анысын инде аңа азаматтай ире Назыйм бүләк итте.

Мәктәп-интернатта ул очрашудан соң күпме сулар акты, күпме җилләр исте. Шәмсия, университет тәмамлагач, Әлмәттә балалар бакчасы мөдире, Казанда китап нәшрияты редакторы булырга өлгерде. Ниһаять, Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясенә күчеп килде. Шул арада улы Илдар, кызы Гөлназны аякка бастырды. Гомер үренә менеп җиткәндә генә, ире үлеп, үзе тол калды. Ләкин тормыш киртәләре алдында җебеп төшмәде, телен аркылы тешләп булса да түзде, ыңгырашмады, сыкранмады. Ә күңеленнән һаман ак шигырьләр акты.

Моңа кадәр белмәгәнмен генә —
Төннәр озы-ы-ын икән...
Сагыш белән шатлык арасында
Бер кул сузым икән...

Белмәгәнмен: мамык юрганның да
Җылысы юк икән...
Ялгызларның сабыр коелары
Тум-тулы ук икән.
Гел елыйсы гына килеп тора —
Кич тә иртән икән...
Җаның саклап сине бер чеметем
Өмет йөртә икән...

Шәмсия Җиһангирова шигырьләре табигый агышлы, халыкча әйтсәк, җырлап тора. Мөгаен, шуңа күрәдер дә композиторларыбыз аның иҗатына аеруча еш мөрәҗәгать итәләр. Бу хезмәттәшлекнең гүзәл җимешләре булып бик күп мәшһүр җырчыларыбызның репертуарын баетырдай әллә никадәр җырлар туды. Алар камил эшләнешләре белән генә түгел, тематик яктан да отышлы. «Нишлим», «Тик син диеп» (Ф.Әхмәт көе), «Ни өчендер безнең язмыш шундый», «Ниләр җитмидер күңелгә» (Л.Батыр-Болгари), «Ак күлмәгем», «Пар канатлар» (И.Дәүләтшин), «Син мине күрмәдең» (Ә.Бакиров), «Мөслимем», «Үзең килгәч, күрерсең» (А.Хөсәенов), «Онытмаган булсаң» (З.Хәйретдинов), «Күрәсем килгән иде» (Г.Сәйфуллин), «Бураннар» (Р.Нәгыймов), «Минем кадерлеләрем» (М.Гыйләҗев) — болары әле телдән төшмичә җырлана торганнары гына.

Шагыйрә, нигездә, мәхәббәт турында яза. Хатын-кыз иҗатчыларның ул темага еш мөрәҗәгать итүенә гаҗәпләнмәскә кирәктер. Чөнки хатын-кыз йөрәге күңел тибрәнешләренә сизгеррәк: елмаюлы карашны да, иркә сүзне дә, кимсетү-кыерсытуны да, хыянәт-алдашуны да нечкәрәк тоемлый. Хисләре ихластан ташып чыга, шуңа күрә сүзләре дә ир кешеләрнекенә караганда ышандырырлыграк булып яңгырый. Аларда конкрет вакыйга, конкрет шәхес, конкрет тормыш мизгеле өстенлек итә. Кешеләрнең язмышы күпмедер дәрәҗәдә бер-берсенә охшаш бит — шуңа күрә бүтән йөрәкләрдән ургып чыккан кичерешләр дә үзеңнеке кебек, үз булып кабул ителә. Сәнгатьнең гомумиләштерү дигән таләбенә, күрәсең, шул юл белән дә ирешеп буладыр.

Шәмсия казна арбасын гомере буе төптән җигелеп тартты: чыгымчыламады, башкалар чиләнсен әле, димәде — аларга салынмады. Табигый сәләте өстенә Ходай Тәгалә аннан тырышлык, үҗәтлек, кешеләргә ихтирам хисе, ачык йөз, татлы тел

дә кызганмаган булып чыкты. Ә болар радиода эшләү өчен иң кирәкле сыйфатлар. Мин, нәфис тапшырулар буенча баш мөхәррир буларак, аны музыкаль редакциягә эшкә кодалаганда, әдәби мөмкинлекләрен яхшы белсәм дә, ул бу шактый четерекле һөнәрне шулай бик тиз үзләштерер дип һич кенә дә уйламаган идем. Ә Шәмсия бер-ике атнадан ук тәртә арасына керде. Тәҗрибәле мөхәррирләр белән уздырыштан тапшыруларны әзерли башлады. Кешеләр белән уртак тел таба алу сәләте, язучыларның, шагыйрьләрнең, композиторларның, җырчыларның иҗатын якыннан белүе нәтиҗәсендә аның тирәсенә әллә никадәр талантлы кешеләр тупланды. Мин кайчакларда гаҗәпләнеп тә куя идем, ничә карасаң, аның эш бүлмәсендә кеше: кайсы җыр тексты күтәреп килгән, кайсы үзенең иҗат кичәсенә чакыра, ә кайсына төпле-акыллы киңәш кирәк. Икенче карасаң, ул җөмһүриятебезнең ерак төбәкләреннән урап кайткан: мавыгып, андагы һәвәскәр артистлар турында сөйли, алар иҗатын халыкка җиткерү турында хезмәттәшләре белән киңәшә.

Бер уйлаганда боларның әдәби иҗатка бернинди катышы юк төсле тоелуы мөмкин. Әмма... әмма ләкин бер генә гөл дә ялгыз үсми бит. Үссә дә, хәлсез, зәгыйфь була. Кешеләр белән нык аралашып яшәгәндә генә, тиңнәрең белән киңәш-табыш иткәндә генә иҗат дигән тылсымның асыл мәгънәсен аңлыйсың, үзең дә өскә, кояшка таба үреләсең. Аның бөтен хикмәте дә шунда.

Гыйбрәтле бер мисал. Моңарчы шагыйрәнең сатира һәм юмор белән алыш-биреше ни дәрәҗәдә булгандыр — ул кадәресен белмим. Ә Татарстан радиосында атнага бер яңгырый торган «Хәерле иртә» тапшыруын алып бара башлагач, аның талантының тагын бер ягы ачылды — нәзакәтле итеп тә, ачы итеп тә көлә белә икән безнең Шәмсиябез! Соңрак «Казан утлары» журналында дөнья күргән «Ачы бал» исемле юмористик хикәясе бу өлкәдә азау теш чыгарган байтак язучыларны да көнләштерерлек иде. Димәк, алда андый потенция чикләнмәгән.

Татарстан радиосы шагыйрәгә үз тавышын ишеттерү өчен яңа мөмкинлекләр ачты — эфир дулкыннары аша аңа меңнәрчә куллар сузылды. Офыклар киңәйде — ихлас күңелле дуслар

артты. Шәмсия үзе дә бурычлы булып калмады —аларга йөрәк түрендә бөреләнгән шигъри чәчәкләрен бүләк итте.

Ш.Җиһангированың иҗат диапазонын шигъри лирика һәм җыр белән генә чикләп кую белән мин ул кадәр үк хаклы да түгелмендер. Ни өчен дигәндә, укучылар күңелен яулап алган повесть һәм хикәяләр, юмористик әсәрләр авторы да бит әле ул. Язучы туктаусыз эзләнә, үз мәсләген, үз кыйбласын табарга тырыша. Ә бүгенгә ул лирик шагыйрә, мәхәббәт шагыйрәсе буларак күбрәк танылган. Мәхәббәт дигәндә дә — бу төшенчәне киңрәк мәгънәдә аңларга кирәктер. Аның шигырьләрендә, җырларында ул сөю хисе гүзәл табигатьле Мөслим тарафларына, туган авылы Баекка, бәбкәләр куып йөргән Сарашлы су буйларына, газизләрдән газиз әнкәсенә, йөрәк парәләре булган сабыйларына, дусларына, танышларына да юнәлтелгән бит. Шул Баегыннан ярлы гына киенгән, язмышның усал җилләре аркасында сыңар канатлы булып калган Шәмсия илһам кошын тоту нияте белән Казанга чыгып киткән, 10 нчы мәктәп-интернатта сыеныр куыш тапкан, авырлыкларны җиңеп, туктаусыз тормышта үз сукмагын эзләгән. Авылда калган яшьтәшләре рәнҗемәгәннәр, киресенчә, үз итеп, аның «Баегым» шигыренә көй чыгарганнар. Шагыйрәнең иҗат уңышларына сөенеп, аның белән горурланып яшиләр алар.

Бәхетле кеше Шәмсия. Аның сүзләренә язылган җырлар телдән-телгә күчеп йөри, концерт залларында, кунак табыны түрләрендә яңгырый, яшь йөрәкләрне кавыштыра, яшәеш өчен гыйбрәт-сабак бирә.

*Әхмәт Рәшит,*
Г.Исхакый бүләге лауреаты,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе



# I

*Бер олыгаям, бер яшәрәм,*
*Бер сүнәм — бетә көчем.*
*Бер елыйм да бер көләм мин*
*Дүрт юллык шигырь өчен.*

# Ышанам

Бүген әле коеп яңгыр ява —
Мәңге туктамаска охшаган.
Иртәгәсен көлеп кояш чыгар —
Мин ышанам шуңа, ышанам.

Башка кайгы төшсә, дусларыма-
Ишләремә сөйләп бушанам.
Алар гына аңлый хәлләремне —
Мин ышанам шуңа, ышанам.

Яшәр өчен җанда өмет барда
Ышанудан бер дә туктамам!
Кемдер шулай миңа ышанадыр... —
Мин ышанам шуңа, ышанам!

# Бәхетең үз кулыңда

Сорау бирдем агымсуга:
«Бәхет ул,— дип,— нинди була?»
Белсәм, каршы чыгар идем
Чәчәк тотып кулыма.
Минем дә бит бардыр хакым
Бик бәхетле булырга.

Сорау бирдем горур тауга:
«Бәхетем,— дип,— йөри кайда?»
Юлсыз җирдән юллар салып,
Эзләр идем тапканчы,
Бик бәхетле булып кына
Яшәр идем аһ-зарсыз.

Сихри дөнья әйтте миңа:
«Бәхетең,— дип,— үз кулыңда.
Гел алга бар, туктап калма,
Табарсың бәхетеңне.
Аңларсың — дөньяда яшәү
Үзе зур бәхет инде.
Шул үзе бәхет инде!»

* * *

Күзенә карыйм да,
Асылын белергә тырышам
Юлымда очраган кешенең:
Бу нинди кеше, дим.
Мин белгән кешеме?
Әллә соң эчендә
Бөек сер йөртәме?
Бүгене ниндирәк?
Ниндирәк үткәне?
Ышанасым килә,
Бушанасым килә,
Сыенып кешегә:
Нәкъ синдәй кешегә,
Нәкъ миндәй кешегә,
Нәкъ бездәй кешегә...
Кайчакта минем дә
Күңелем күшегә...
Мин дә бит кеше лә!

Гап-гади кеше лә!
Карыйм да... үземә
Мең сорау яудырам:
Бу нинди кеше, дим?
Зур микән
Күләме эшенең,

Замана
Бизмәнгә салдырса?
Ут йота микән, дим,
Ялгышып, аз гына
Кешенең хәтерен калдырса?
Сораса Кешелек,
Ниндирәк кеше, дип,
Әйтерлек булсын, дим,
Бер дигән кеше, дип,
Мәкерсез эче, дип.
Нәкъ синең төсле, дип,
Нәкъ минем төсле, дип,
Нәкъ безнең төсле, дип,
Иң кирәк чагында
Таяныр кеше, дип...
Күзенә карыйм да
Очраган берсенең,
Асылын белергә тырышам
Гап-гади кешенең —
Нәкъ үзем ишенең,
Нәкъ синең ишенең,
Нәкъ безнең ишенең...

# *Яшәүнең үзеннән көч алам*

Син сорама миннән, сорама,
Яшәргә, дип, каян ут алдың?
Ярсу елгалардан,
Горур кыялардан,
Яшәүнең үзеннән көч алдым.

Син сорама миннән, сорама,
Кем, дип, сиңа бәхет юрады?
Аткан һәрбер таңнан,
Якты Кояш-Айдан,
Тормышның үзеннән сорадым.

Син сорама миннән, сорама,
Җырыңа, дип, каян моң алдың?
Урау юллар үтеп,
Авырлыклар кичеп,
Язмышыма таба юл салдым...
Яшәүнең үзеннән көч алдым...
Тормышның үзеннән сорадым...

* * *

Мөкәлләф булганыма бән
Үтте инде дүрт чират.
Беләмен: көтеп тормактыр
Җәннәт күпере — сират.
Үтәмәктәмен шөгыльнең
Фарыз вә ваҗипләрен.
Хәрәм, мәкрух, мөфсидләргә
Нәфсемне бән бикләдем.
Мөбахлар да кылынгандыр,
Булгандыр мөстәһар да...
Рамазанның үзендә дә
Йоклангандыр сәхәрдә.
Бозылгандыр шәһадәтләр,
Гыйбадәтләр, йолалар,—
Дөньясыны басып алгач
«Пәйгамбәрләр», муллалар.
Фани дөнья малларыннан
Рази булып азга да
Ярты гомеремне үткәрдем,—
Баралмадым хаҗга да...
Әмма фарыз бер шөгылем бар
Дөнья буйлап бармага:
Ни кылсам да, гафу сорап
Табынганым — Аллага:
Йа Раббым, ярлыкагыл
Кылган гөнаһларымны.
Тәмуг утында каралтма
Бәнем йөз акларымны.

---

*Мөкәлләф* — бурычны үтәр яшь. Кыз балаларга — 9—12 яшьләр.

*Фарыз* — Аллаһы мәҗбүри үтәргә боерган эшләр.

*Ваҗип* — фарыз кадәр үк мәҗбүри булмаган эшләр.

*Хәрәм, мәкрух, мөфсид* — тыелган эшләр.

*Мөбах* — гөнаһы да, савабы да юк эш.

Ни кылсаң да, кодрәтеңнән
Киләдер синең, бәйнә!
Сиратларны кичкән чакта
Изгеләреңнән әйлә.
Амин!

* * *

Яз иде бит әле,
Яз иде бит!
Кай арада сары көз җитте?
Тәрәзәгә карап уфтандым мин:
Булды да бетте, дип,
Булды да бетте.

Бала идем әле,
Бала идем!
Кайчан гомер уртасы җитте?
Яшьлегемне сагынып уфтандым мин:
Булды да бетте, дип,
Булды да бетте.

Үтеп китәр гомер,
Үтеп китәр,
Йөгереп кенә үткән яз төсле.
Үкенмәскә иде, уфтанмаска!
Булды да бетте, дип,
Булды да бетте...
Яз иде бит әле,
Яз иде бит...

* * *

Яфрак коя-коя, моңсу гына
Күзгә кереп бара агачлар...
Кешеләр дә, табигатькә кушылып,
Агач язмышларын кабатлар.

Агачларга җиңел — язлар җиткәч,
Алар яңа яфрак ярырлар.
Яшәрер бар җиһан. Тик кешеләр
Гомер көзләрендә калырлар.

Ямьле язлар сөендермәс җанны
Баеганда гомер кояшы.
Бар да кала... бар да бездән кала...
Агачы... яфрагы... дөньясы...

* * *

Тормышта мин юллар салып барам,
Кышын карлар ярып барган кебек.
Бара-бара аяк кына түгел,
Йөрәккәем хәтта талган кебек.
Әмма һаман алга бару уем,
Табыласы эзләр калган кебек.

Тормышта мин тешем кысып түзәм,
Чи ярага тозлар сипкән кебек.
Инде бәхет нәрсә икәнлеген
Тоеп яшәр вакыт җиткән кебек.

Тормыштан мин җиңеллекләр көтмим:
Бәхетләрне беркем куймас өеп.
...Шулай өметләнеп яши-яши,
Гомрем чиге килеп җитәр кебек...

* * *

Кояш көткән чакта яңгыр ява,
«Яңгыр!» дисәң, кояш кыздыра.
Кеше шулай бөтен гомере буе
Булмаганны сорап уздыра.

Шатлык көткән чакта кайгы килә,
Көләм дисәм, елыйм нигәдер...
Адәм баласына бу дөньяда
Бары да чиратлашып киләдер.

Сөю көтеп гомер үтеп бара...
Чәчемдә чал күреп уфтанам.
Хәле миннән мөшкелләрне күреп,
«...Шөкрана!» диеп тукталам.

Өмет итмим бары бәхет кенә!
Кайгысы да булсын, зары да...
Язмышыма нәрсә язылса да,
Тансык миңа бары-бары да...

* * *

Зиратларга керсәм, хәйран калып
Карап торам кабер ташларына —
Күпме асыл Хода бәндәләре
Кереп яткан җирнең асларына.
Җир өстенә алар һәммәсе дә
Бары бәхет эстәп килгәндер.
Һәм күбесе бәхет ни икәнен
Белә алмый гүргә кергәндер.
Кайберләре, бәлкем, бар гомерен
Байлык җыеп сарыф иткәндер,
Шушы юлда күпме хилаф кылган,
Күпме кешене рәнҗеткәндер.
Әмма бар мөлкәте җирдә калган —
Үзе белән берни алмаган.
«Байлык булса, суд та, чурт та юк!» — дип,
Аны иблис-шайтан алдаган.
Кайберәүләр намус белән яшәп,
Ап-ак күңел белән киткәндер;
Сиратларны җиңел генә кичеп,
Оҗмах түрен нурлы иткәндер...
Язулы таш иле — Каберстан,
Кайчан килмә — үлем салкыны,
Яшәү дигән сүзнең җылылыгын
Тоям шушы салкын аркылы.
Язмасын ла, димим, миңа Ходай
Кара гүргә беркөн керергә...
Анысы булыр. Язсын иде бары
Чиста намус белән үләргә.
...Зиратларга керсәм, хәйран калам,—
Кабер саен ташлар утыра...
...Тагын кемнең җанын сорый икән —
Шомлы итеп козгын кычкыра...

# Үкенмәмен

Үкенмәмен нигә туганыма:
Үзем булалмастай чагымда да
Үзем була алсам,
Авырлыклар килсә, егылмыйча,
Аягүрә калсам.

Үкенмәмен җирдә яшәвемә:
Кызыксыз тоелган нәрсәне дә
Кызык итә алсам,
Зарланмыйча, уфтанмыйча гына
Гомер итә алсам.

Үкенмәмен, ник яндым икән, дип,
Башкаларны кабатламый гына
Матур шигырь язсам,
Шул шигырем белән ир-егетне
Шагыйрь итә алсам.

Үкенмәмен җирдән китүемә:
Үземнән соң гел яхшылык белән
Халкым искә алса,
Җан дусларым килеп каберемә
Бер уч туфрак салса...

* * *

Ел фасылы алмашынган саен,
Уйланам мин һаман, уйланам.
«Яшьлек үтте...» — диеп уфтанмыймын,
«Язлар булды!» — диеп куанам.

Күзләрендә сары төскә чумган
Агачларга барып сыенам.
«Гомер уртасына җиттем...» — димим,
«Көзләргә җиттем!» — дип сөенәм.

Үтеп китәр гомер, үтеп китәр,
Беркем аннан читтә калмаган. —
Язмышыма мең рәхмәтләр укып,
«Кышларга җиткер...» — дип ялварам.

* * *

Тәрәзәдән карап утырам мин.
Ишеп-ишеп ява март кары...
Табигатьнең кыштан арынмаган,
Язга табынмаган бер чагы.

Ишелеп-ишелеп тула җанга сагыш...
Куу-кумау гайре файдасыз.
Гаҗизлектән мине йолып алыр
Галиҗәнап дуслар, кайда сез?!

Аңлап булмый фани дөнья хәлен...
Ишеп-ишеп ява март кары...
Аһ! Үзем дә гайре ихтыяри
Әлле-мәлле чагым... Март чагым...

* * *

Җиргә язлар килә,
Кояш шашып көлә.
Тулып пешкән әнә бөреләр.
Менә-менә күзен ачарлар да
Бар җиһанга сәлам бирерләр.

«Сәлам» диеп, «сәлам»
Эндәшер бар галәм.
Кошлар җырлап җавап бирерләр.
Язлар җиткән чакта безнең дә бит
Пешеп тулган чак ул күңелләр.

Гел көләсе килә,
Гел сөясе килә,
Бар җаныңны биреп-таралып.
Яшеллек иленә,
Әйдә, бергә-бергә
Керик әле, дуслар, агарып!

* * *

Көзге җилдә өем-өем
Яфраклар тарала.
Инде онытылып барган
Хатирәләр яңара.

Һәр көн шулай: яфраклар
Бер өелә, бер туза.
Әкрен генә, салмак кына
Күңелләрдән көз уза.

Агачыннан өзелеп төшкән
Яфрак еракка китә.
Көзге җилләр, шул яфрактай,
Күңелне язга илтә.

## *Көзге этюд*

Көзнең соңгы ае...
Көн уртасы,
Сукмак буйлап атлыйм ялгызым.
(Парлыларның гына юлы кыска,
Ялгызларга сукмак та озын...)
Күңелемдә бушлык...
Уйлар, көйсез әби кебек,
Башкаема керми йөдәтә.
Шуңадырмы
(Минем өчен гайре табигый хәл),
Тирә-юньне әрсез күзәтәм.
Әнә
Иске өйне яндырганнар —
Яшь каенны өткән ялкыны.
Каенкайның кара кәүсәсендә
Тормыш түгел — үлем шаукымы...

Тыңлап тордым чырык-чырык иткән
Көзге песнәкләрнең җырларын.
Мендәр сүткән кебек пыр-пыр килеп,
Саесканның очып узганын.
Көзге яфракларга борын төртеп,
Эт малае йөри иснәнеп,
Карт наратка кунган тукранның
Күлмәгенә исең китәрлек:
Башы — кызыл кәпәч кигән кебек,
Койрык очы ачык ямь-яшел...
Янәшәдә ялгыз ихатадан
Җыры ишетелә әтәчнең...
Тын һавада тәмле төтен исе,
Мунча якканнардыр, ахрысы...
Рәхәт сыман булып китте яшәү,—
Барган саен килә атлыйсы.
Атлыйм һаман адым саный-саный,
Таулар төштем, мендем үрләргә...
Зират тирәсенә җиткәнмен бит,
Ә зиратта... кеше күмәләр...
Шушы көзге хозурлыкны ташлап,
Китә кемдер соңгы сәфәргә...
Песнәк, әтәч, тукран, этләр белән
Мин яшәргә телим, яшәргә!
...Тау астында тормыш кайный иде.
Үрләрендә — кабер тынлыгы.
Юк, кирәкми. Кермим зиратларга.—
Мин... Тормыш ягына борылдым...

* * *

Бар табигать инде көзгә кергән...
Күрегезче! Күрче, миләшне! —
Кызыл тәлгәшләре хәтерләтә
Уттай янып торган йөрәкне.

Кемдер әйтер: «Инде көзгә кергәч,
Яну-көю мөмкин түгел»,— дип...
...Кулга-кул тотынып икәү бергә
Миләшләргә каршы йөгердек.

Күпме кызарса да, җимешләре
Ачы шул, нигәдер бик ачы... —
Яныйк әле ачы әрнүләрдә,
Сөю хисен татып, туйганчы!

...Өзмәсәләр, салкын кышларда да
Уттай янып тора миләшләр...
...Ак кар өсләрендә сулкылдаша
Йөрәк кебек кызыл тәлгәшләр.

Яныйк әле без дә, миләш кебек,
Дөрләп, көзләрен дә, кышын да...
Бу дөньяның бөтен асылы да,
Яшәү кадере дә шушында!

* * *

Һәр фасылы газиз, дибез дә бит
Җир-ана дип йөрткән бу йортның,
Никтер быел көзне үткәрәлми,
Кышны җиткерәлми борлыктым.

Күңелләргә сагыш булып тулды
Алтыннардай яфрак сарысы.
Урманнарга чыгып киту түгел,
Тәрәзәдән килми карыйсы.

Кинәт кенә үтеп киткәч җәе,
Озакка сузылгач көзләре,
Сары яфрак asларыннан, иелеп,
Ап-ак төсен кышның эзләдем.

Куркытса да җәйле күңелемне
Зәмһәририрле кышның салкыны,
Көзләреннән мәгънә табалмыйча,
Мин кышларга һаман алкындым.

...Бүген менә карлар явып киткән.—
Бар мохитне баскан кар исе.
Көздән китә алмый тилмергәндә
Кышлары да икән ярыйсы...
Бар җанымны баскан кар исе...

* * *

Чиста җаным белән аваз салам:
— Нихәл, Аклык иле, исәнме?!
Алтын көзләр белән артык мавыгып,
Сизми калдым
Синең ничек килеп җиткәнне.

Аклык тели күңел, аклык тели,
Бурап-бурап ак кар яуганда,—
Чистарасы килә карда аунап,
Дөнья карасыннан һаман да!

Бөдрә буран! Бөтереп ал да җанны,
Алып китче Аклык иленә!
Бушансын бар җаным
Һәм артсын иманым —
Ышанычым бүген син генә!

Син генә тик! Сүрәнләнгән җанга
Ут салучы сүнеп барганда...
Бураннарга төреп җылыт мине, зинһар,
Мин янарга телим! Янарга!

* * *

Ак каенда — аклык, сафлык төсе,
Кешеләргә сыймас сер анда.
Өй буена түгел, юл буена
Утырталар аны шуңа да...

Илен ташлап читкә китүчеләр
Ак каенга сарылып елаган.
Яшь йөрәкләр сихри тын кичләрдә
Эч серләрен сөйләп юанган.

Безнең сагышлардан саргайса да
Яфраклары көзләр җитүгә,
Кәүсәләре ләкин ап-ак килеш.—
Алар һаман пакьлек төсендә.

Каенкайлар, гүзәл каенкайлар,
Мин дә сезгә сөйлим серемне:
Мәңге саклагыз сез һәм аклагыз
Татарстан дигән илемне.

## *Шулай, димәк*

Күземә ак-кара күренмичә,
Барсам нидер сөйләп.
Читтән генә карап кал син миңа —
Бүген шулай кирәк.

Өемне танымый үтеп китсәм,
Баш әйләнгән, димәк.
Андый хәлләр минем тормышымда
Була бик-бик сирәк.

Карга ятып аунасаң да сүнмәс —
Җаным яна дөрләп.
Кайтып киләм халкым каршысыннан
Яңа шигырь сөйләп.

* * *

*Румыниядән килгән*
*Кыйммәт ханым Мәмәткә*

Кайда куйсаң, шунда кыйммәт,
Чук-чук гүзәл Кыйммәт ханым,
Сине уйлар, сине сагыныр
Һаман-һаман төрки җаным.
Җырладың син яшь аралаш
«...Кырым кызы, Кырым кызы...»
Сине тыңлап, күңелемдә
Кабынды милләт йолдызы.
Кай мәмләкәт, кай илләрдә
Сыкрый синең милли җаның,
Йолдыз кебек чук-чук гүзәл,
Мәңге сүнмәс Кыйммәт ханым?!
Нинди хис бу?! — Бер анадан
Туган кебек якыннар без.
Җан тартмаса, кан тарта, ди.—
Бер үк кан без, бер үк җан без —
Бер татар без.
Шулай булгач, гаҗәп түгел
Күрешкәндә елашулар...
Сорыйк әле бер Ходайдан —
Насыйп булсын очрашулар.

*07.05.99. Истанбул*

* * *

*Илфар Кәрим улы Сабировка*

Кырык тугыз әле илле түгел,
Җил-давыллар булып җилли күңел.
Әле бөтен дөнья шау чәчәктә,
Якты уйлар гына киләчәккә.

Кырык тугыз — илле бусагасы,
Ярты юлда туктап бушанасы.
Алып аннан яңа егәр җанга,
Ыргыласы һаман алга! Алга!

Күпме эшләр инде эшләнгән дә,
Күпмеләре алда көтеп тора.
Өлгерерсең! Көч тә, теләк тә бар —
Сиңа әле кырык тугыз гына.

## *Ходайга ялварам иң элек*

Яралы җанымны бәйләп куйган
Төеннәрем китсә өзелеп,
«Рәхмәтеңнән мине ташлама...» — дип,
Ходайга ялварам иң элек.

Дөнья тулы кеше арасында
Ялгыз башым йөрсәм тилмереп,
«Җәзалама ялгызлык белән...» — дип,
Ходайга ялварам иң элек.

Башкаема урын табалмыйча,
Ят иңнәргә куйсам иелеп,
«Гөнаһларым ярлыкагыл...» — диеп,
Ходайга ялварам иң элек.

Чарасызлыкларга түзалмыйча,
Күз яшьләрем койсам илереп,—
«Сабыр арты сабырлыклар бир...» — дип,
Ходайга ялварам иң элек.

Күз яшьләрем кибә, җан төзәлә,
Йөрәгемә килә җиңеллек,—
Бар икәнен, бер икәнен белеп,
Ходайга ялварсам иң элек.

Әгәр мине Ходай ташламаса,
Беләм авыр чаклар үтәсен.
Чарасызлыклардан чара табып,
Морадыма берчак җитәсем.

## *Кем ничек*

Кемнәрнеңдер акчасы бар, бакчасы юк.
Кемнәрнеңдер бирәсе бар, аласы юк.
Кемнәрнеңдер хатыны бар, баласы юк.
Кемдер гомерен үткәрә эчеп, тартып.
Кемдер дан-шөһрәт казана, намус сатып.
Кемнәрнеңдер аты бар да, йөгәне юк.
Кемнәрнеңдер ире бар да, сөйгәне юк.
Кемнәрнеңдер әнисе бар, әтисе юк.
Кемнәргәдер бәхет мәңге тәтисе юк.
Кемнәрнеңдер ашлары бар, итләре юк.
Кемнәрнеңдер башлары бар, битләре юк...

* * *

Кич саен юатам үземне:
«Иртәгә башкача көн туар!»
Барысы да булыр, дим, башкача,
Торса да каршымда таш дивар.

Баш төнлә шәп эшли! Шаккаткыч!
Алда мин үтәсе киң юллар...
Иртәсен күземне ачуга,
Каршымда — кичәге таш дивар!

* * *

Күңелемне юатырга
Бетсә соңгы чарам —
Хәсрәтләрдән арынырга
Кешеләргә барам.

*Шәриф Биккол*

Тупас җаннар бәрелеп күңелемә,
Ачылып китсә ярам,
Яраларым кысып бәйләтергә
Үз-үземә барам.

Ялгыз гына көләм, ялгыз елыйм,
Ялгыз гына янам.
Мең сорауга мең дә бер җавапны
Үз-үземнән табам.

Рәнҗетсәләр әгәр нахак сөйләп,
Кара итеп һаман,
Үпкәләмим, чөнки барыбер мин
Үзем булып калам.

Беркатлы чакларым үтте инде,
Анык әйтә алам:
Мин, кешеләр, сезгә бармыйм хәзер,
Үз-үземдә калам!

* * *

*Дәрдемәндчәрәк*

Әнкәй, бәгърем, ни дип яраттың мине
бу тормышка?! —
Өйрәтмәгәч ялагайлык, хөсет һәм дә орышка.
Әйтче, ни дип ак җаныңны бүлдең син
дүрт кисәккә?! —
Алынмагач борчу, мәшәкать вә кайгың исәпкә.
Нинди уй вә гамь белән китердең дөньяга
дүрт кызың?! —
Аларга да теләмәгәч бәхет-рәхәтне озын.
Ни дип күрсәтмәдең миңа бәхет кыйбласының
кайдасын?! —

Булса бәхтем, син дә күрер идең бер-бер
файдасын.
Әнкәй, бәгърем, ни дип аттың мине
тәмуг эченә?! —
Ширбәттер дисәм, һәркайсы көчләп агу эчерә...

* * *

*Тукайчарак*

Бер кешегә юк эчемдә каралык,
Яхшылыктан китә җаным таралып.
Күктәге йолдыз санынча бәхетем
Арткан саен тора һаман яралып.

Дошманнарым таш ыргытса йөземә,
Нахак әйтсә бәреп әгәр күземә,
«Һау» да «һау» дип әрепләшмим, тик торам,
Җәзасын бирер диеп бер Ходам.

Бу халәтем түгел куркаклыгымнан,
Ходай бирмеш — бары җан аклыгымнан.
Кызганамын хөсетне шул минутта,
Янар бу, дип, берчак җиде тәмугта.

Яшәвемнең төп асылы бер генә,
Ходам белә. Инде белдең син менә:
Егылырмын таеп шул мәл һуштан мин —
Дус итсә гәр мине берәр дошманым.

* * *

Бөгелмәм, дидем. Бөгелдем —
Таллардан күреп микән?
Күзләремдә моң чайпала —
Чишмә түгелеп микән?
Сарылмам, дидем. Сарылдым
Ялгыз каен иңенә.
Көзге яфрак сарылары
Инде мәллә йөземә?
Өзелмәм, дидем. Өзелдем,
Өзелгән гөлләр кебек.
Таҗларымны җилләр йөртә
Дөньяга чәчеп-түгеп.
Бөгелсәм дә, өзелсәм дә,
Сыгылсам да, сынмадым.
Ялгыз каен белән пар мин —
Ялгыз башым булмамын.

* * *

Нәрсә булды әле?
Бер чеметем нурга
Сөенә белә идем.
Җилсез очып китәр кайгыга да
Көенә белә идем.

Нәрсә булды әле?
Сөендерми җанны
Яз гөлләре, көзләрнең сарысы...
Килми... өелеп яткан бәхеткә дә
Абынып карыйсы.

Нәрсә булды әле?
Күңелем энҗеләрен
Бетердемме әллә күпләп сибеп?
Алдандыммы кергә батып беткән
Дөньясына нур өстәрмен диеп?

Нәрсә булды әле?
Фәкыйрьләде җанны
Битараф күңелләр өермәсе.
Килми беркемгә дә табынасы...
Килми сөеләсе...
Елап китә белмим,
Сагынып кайта...
Шул булдымы яшәү нәтиҗәсе?!
Каралыкка бәрелеп — чәлпәрәмә!
Күңелемнең тирән почмагына
Сыенып калган Аклык хатирәсе...

* * *

Бар табигать суга тилмергәндә,
Ямьле җәй көнендә, чилләдә,
Тамыр җәеп үскән агачларның
Яфрагына эссе тигәндә,
Син күтәреп кайттың кеп-кечкенә
Шомырт белән миләш куагы.
«Мин яшисе булсам, үсәр...» — дидең,
Теләккәең кабул булмады.
Әҗәл тырнагына бирмим, диеп,
Тырышсам да ялгап көнгә төн,
Кара үлем барыбер тартып алды,
Акланмады минем өметем,
Акланмады синең өметең.
...Гомерләрең, никтер, кыска булды,
Бик әз тордың якты дөньяда.
...Кара күзең булып шомырт карый,
Иренең булып миләш елмая...

* * *

Моңа кадәр белмәгәнмен генә —
Төннәр о-о-з-з-ы-н икән.
Шатлык белән кайгы арасында —
Бер кул сузым икән.

Белмәгәнмен: мамык юрганның да
Җылысы юк икән.
Ялгызларның сабыр коелары
Тум-тулы ук икән.

Гел елыйсы гына килеп тора —
Кич тә иртән икән...
Җаның саклап сине бер чеметем
Өмет йөртә икән.

Кешеләрнең яхшы сүзләре дә
Кайчак агу икән.
Иң читене — гомер уртасында
Ялгыз калу икән...

* * *

Сикереп кенә атланыр да идең...
Атлары шул ап-ак бүз түгел.
Кем беләндер бергә булу әле
Ялгыз булмау дигән сүз түгел...

Булса булсын атның тик акбүзе —
Башка атлар безгә үз түгел...
Кем беләндер бергә булмау әле
Ялгыз булу дигән сүз түгел...

* * *

Бәгыремә тиде салкын,
Туң катырды күңелемне.
Сагынып искә алыр чагым
Элек болай түгелемне.

«...Сабыр,— дидем. Сабыр иттем,—
Бәхет килер тулып-тулып...» —
Кайгылардан сулган җанны
Салкын кырау китте сугып.

— Кайсыгызның кулы җылы —
Килегез! — дип салмыйм сөрән. —
Җан терәлмәскә тән терәп
Җылыналмасым яхшы беләм...

Арагызда бармы минем
Хәлгә керер берәрегез —
Кырау суккан йөрәгемне
Үз җанына терәрегез?!

...Әллә сезнең дә, минем күк,
Кырау суккан көнегезме? —
Хәлем җитәр җылытырга
Арагыздан берегезне...

# *Хәлемне сорамагыз*

«Син түзәсең»,— димәгез лә,
Килми түзәселәрем.
Килә шатлык диңгезләрен
Иңләп йөзәселәрем.
Килә барып сыенасым
Иңнәренә ир-атның...
Түзә-түзә хатын-кызлык
Горефләрен югалттым.
Көнләшмәгез: ир-ат кебек
Җиңә, дип, авыр эшне.—
Хатын-кыз ул кайчак көчсез
Булуы белән көчле.
Сөйләп йөрмәгез кешегә:
«Ул бит бераз юләр,— дип.—
Еламас җирдә дә елар,
Көлмәс җирдә көләр»,— дип.
Аптырамагыз сүземнең
Онытылса азагы.
Сез белгәне агы гына,
Җанда барлык газабы...
Күргән төшләрем сөйләсәм,
Начарга юрамагыз.
...Авыр булмасын дисәгез,
Хәлемне сорамагыз...

* * *

*Үз-үземә...*

Җилфер-җилфер генә искән җилләр
Чәчләрең тузгытып китәр инде...
Кырыгың да тулмас борын сине
Кайгы-сагыш харап итәр инде...

Үкенерсең, бәгырьләрең өзелеп,
Зая үткән гомер саннарына...
Күшегер лә күңелең көннән-көнгә
Сыенып кеше тапмый җаннарыңа...

Үз-үзеңне юаткан булырсың
«Ярый әле, балалар бар...» — диеп...
Күңелкәең генә боек калыр
Кояшка тилмергән чәчәк кебек...

* * *

Нигә күңелләрең боек —
Сагышлар эчтең мәллә?
Сөйгән ярың ташладымы,
Калдырып авыр мәлдә?

Нигә башың түбән идең —
Таяныр кешең юкмы?
Күзләреңдә яшь бөртеге —
Сагышмы, моңлылыкмы?

Имә башың, койма яшең! —
Сизмәсен дошманнарың.
Дошманыңнан да бигрәк —
Дус дигән куштаннарың...

* * *

Дөньям җитеп ашкан кебек минем,
Фатирым бар, хәтта машинам.
Улым белән кызым, яхшы туным...
Бөтен-бөтен нәрсәм бар сыман.

Кайчан телим — шунда кайтып керәм,
Кая телим — шунда баралам.
Кул арама кереп, «әнием» дип,
Үлә язып тора балалар.

Дусларым да, хәтта дошманнар да
«Бәхетсез» дип әйтә алмыйлар.
...Ә мин менә һаман шигырь язам,—
Бәхетлеләр шигырь язмыйлар.

# *Әгәр үлә калсам...*

*(Ярым моңсу шаяру)*

Минем үлем сенсация булмас! —
Шаккатмыйлар Туфан үлеп тә...
Ярап торыр (сатып алалсалар!)
Самосыровога күмелсәң.
Шалтыр-дөбер матәм уйнатмаслар...
Кемнәр елар, кемнәр еламас...
Хәер! Анысын минем мәңгелеккә
Йомылган күзләрем күралмас.
Кемдер эчтән генә: «Чукынды!..» — дип,
Тәһарәтсез итәр әппәрен...
Ләкин... синең чиста күңелеңдә
Мәңгелеккә калыр ядкәрем.
Эчтән генә өзелеп еларсың син,
Кешегә күрсәтми яшеңне...
Ә мин сиңа, хәтта үлем аша,

«Бердәнберем!» — диеп дәшермен.
Мөһим булмас саран нотыклар да,
Ялган мактаулар да кирәкмәс!..
Рәхәт булыр өзелгән җаныма
«Хуш, матурым!» диеп, син дәшкәч...
Үле тәнем кара җир алса да,
Җаным җиде күктә нур чәчәр,
Киек Каз Юлында йолдыз булып
Синең җанны көтеп мең яшәр.
Бөтен җаннар күктә кавышмаса,
Киек Каз Юллары каралыр...
Җаным җирдә туган бер сабыйның
Җаны булып кабат яралыр...

* * *

Сипмә лә, язмыш, тозыңны учлап
Еллардан калган яраларыма.
Фани дөньяга яраклы булып
Җаным тик яңа ярала гына.
Сынама мине! Сынама! Җитәр!
Сабырлыгымны белдең бит инде.
Өмет өзелсә фани дөньядан,
Җаным таралып китәр шикелле.
Гел ачык тотма Фал китабыңның
Безгә бәхетләр язмаган битен...
Әнкәм дөньяга тудыргандыр бит
Мине, мөгаен, бәхетләр өчен.
Булды микәнни рәнҗегән чагы
«Бәхетләр күрми гомергә үтсен...» — дип.—
«Гомер чигенә барып җиткәнче
Сабырлыклары сынып бетсен...» — дип.
Рәнҗегән булса, тәүбә иткәндер
Ходай каршында бөгеп билләрен,
«...Фани дөньяда күрсәйде,— диеп,—
Ике дөньяның рәхәт көннәрен...»

Кабул кыл, Ходай, кабул кыл, Ходай,
Газиз әнкәмнең шушы теләген,—
Күрәсем килми «Бәхете булмады
Баламның» диеп әрнеп үлгәнен...
Берәр чеметем шатлыклар да сал
Кайгы чоңгылы араларына.—
Бала кайгысы бирмә әнкәмә,
Ана кайгысы — балаларыма...

* * *

Гомерем буе йокыдан
Әнкәм уятты сөеп:
«Тор, әйдә, кызым, тор инде,
Йокың туйгандыр»,— диеп.
Кемдер мине рәнҗетсә,
Юатты баштан сөеп:
«Шул бәндәдән гыйбрәт ал,
Син алай булма»,— диеп.
Сәфәр чыксам ерак юлга,
Әнкәем калды көеп:
«Китәсең лә, бәбекәем,
Юлларың уңсын»,— диеп.
Гел яхшылыкка өндәде,
Йә шелтәләп, йә сөеп:
«Кеше сиңа таш атса да,
Син ашыңны ат»,— диеп.
Дөнья гамьнәренә чумып,
Башымны куйсам иеп,
Әнкәй хәзер килеп җитә:
«Хәсрәтең бармы?» — диеп.
Әнкәемнән мәхрүм калсам,
Кемнәр юатыр сөеп:
«Нигә башың түбән идең,
Хәсрәтең бармы?» — диеп...

* * *

Мөэмин рамазан ае бүген:
Әнкәй уразага кергәндер,
Кояш уянганчы сәхәр ашап,
Намазлык өстенә менгәндер...
Бер-бер артлы шулай укыгандыр
Икендесеннән соң ахшамын,
Ясигыны үткәч, пешергәндер
Биш кешелек итеп ашларын.
Дүрт кызына бетмәс бәхет сорап,
Бер Тәңрегә сәждә кылгандыр;
Чандыр кулын каш өстенә куеп,
Олы юлга карап торгандыр.
«Шәмсия булмаса, Әлфиясе
Кайтып килер...» — диеп көткәндер.
«Авыз ачкач, кичке ашны бергә
Ашарбыз...» — дип өмет иткәндер...
«Бала күңелләре — далада...» — дип,
Эчтән генә уйлап куйгандыр.
«Ярый... исән генә йөрсеннәр...» — дип,
Үз-үзен юаткан булгандыр...
Бөтен авыл йоклап беткәч кенә
Әнкәемнең уты сүнгәндер...
Көне буе уйлар уйлый-уйлый,
Төшләрендә ниләр күргәндер?
...Мөэмин рамазан ае бүген —
Әнкәй уразага кергәндер...

* * *

Бала чактан күптән киттем инде,
Колагымда чыңлый ник һаман:
«Авызыңа шайтан керер юкса,
Әппәреңне иттеңме, балам?!»

«Шайтан» дигән сүздән уттай куркып,
Чынга алып әнкәм әйткәнне,
Бер урынына ничә йөз мәртәбә
Әйтә идем «Аллаһу әкбәр»не.

...Ходай биргән нигъмәтләрне җыеп,
Кайчан ерак юлга кузгалам —
Колагымда чыңлый әнкәм тавышы:
«Әппәреңне иттеңме, балам?!»

## *Минем әнкәй дә картайган инде...*

Минем әнкәй дә картайган инде —
Йөгереп йөрми башлаган инде.
Күзлеккә сылтый начар күрүен,
Энәгә җепнең авыр керүен.
Минем әнкәй дә картайган инде —
Күңеле тула башлаган инде.
Хәтере кала ярты сүздән дә,
Сөенә хәтта ялгыш көлгәнгә.
Минем әнкәй дә картайган инде —
Исемнәр бутый башлаган инде —
Дәшәсе килсә тик беребезгә,
Саный ул безнең дүртебезне дә:
...Әнисә... Халисә... Әлфия... Шәмсия...
Минем әнкәй дә картайган инде —
Саннарны белми башлаган инде:

«Таптым,— дип,— сине мин утыз биштә,
Миңа җитмеш биш... ә сиңа ничә?»
Минем әнкәй дә картайган инде —
Бераз хәйләли башлаган инде —
Белеп тора ул минем яшемне,—
«Кырык тулды...» — дип һич әйтмәсемне.
Гаҗәпкә калып, карыйм үзенә —
Әнкәй дә кебек, әнкәй түгел дә...
Мин карыйм аңа... Ул карый миңа:
«Картая,— дидер,— минем кызым да...»

* * *

Әнкәй, бәгърем, беләм синең чәчләр
Нигә шулай иртә агарганын.
Ипи-тозга риза булып яшәп,
Бу дөньяда бәхет табалмадың.

Минем язмыш нәкъ бертөрле түгел,
Бераз гына кайтыш — үзгә синнән.
Ипи-тозга гына риза булмый,
Кайчак, чумып, балда-майда йөзәм.

...Авыл түгел инде. Шәһәрдә бит
Офыкларның чиге ераграк....
Шуңадыр да, бәхетләргә илтер
Юллар уравырак, бормалырак.

Беләм хәзер чәчләремнең нигә
Кырык тулмас борын агарганын:
Син эзләп тапмаган бәхеткәйне,
Әнкәй, бәгърем, мин дә ... табалмадым!

* * *

Үдебедчә, «кыдыл бодау»ларча
Дәшим әле сиңа, инәкәем.
Кайта алмыйм һаман яннарыңа,
Ни хәлең бар икән, бәгырькәем?

Саесканнар «кунак чакыра»дыр,
Юкка ымсындырып күңелкәең.
...Миндә дә шул фани дөнья гаме,
Тормыш мәшәкате, инәкәем.

Абынам да торып чапкан булам,
Калышмыйм дип дөнья арбасыннан.
Тоттырмаска күпме тырышсам да,
Гомер миннән өлгер чаба сыман.

Куып җитәр, узып китәр кебек,
Мин калырмын кебек «авыз ачып».
Туктап ял итәргә кирәктә дә
Куалыйм үземне ярсып-ярсып.

Менә шулай үтеп бара гомер...
Акланырлык тагын ни әйтәем?!
«Кайтам!» диеп, һаман алдашканга
Кичер мине, кичер, инәкәем!

* * *

Рәнҗемә миңа, инәкәем,
Хат язмыйча тилмерткәнем өчен.
Җәяү барып җитмәс җирдә яшәп,
Сагындырткан, көйдерткәнем өчен.

Рәнҗемә, денсез булмасам да,
Уразалар тотмаганым өчен,
Бала чакта, башка сабак укып,
Намазларың отмаганым өчен.

Рәнҗемә ак чәчләрең өчен,
Йокысыз үткәргән төннәр өчен...
Рәнҗемә, күз нурыңны түгеп,
Үстергәнмен, диеп,ниләр өчен.

Рәнҗемә: «Әни янына,— дип, —
Онытты бу елга бер кайтасын...»
Онытмадым! Һәр көн куркып яшим,
Белеп яшим... кемне югалтасым...

* * *

Мин дәвамы булып яралганмын
Бу дөньяга әнкәм — асыл затның...
Әнкәемнең итәк чабуына
Асылып калды
Тәпи басып киткәч...
Асыллыгы минем бала чакның.

Мин асыл кыз идем! Шәйләмичә,
Асылындым агач черегенә...
Җил-давыллар алган
Асылымның
Сибелеп калды биткә... көле генә.

Асыл бала... Асыл кыз идем дә...
Булалмадым, никтер, асыл хатын...
Кулъяулыкка җыйдым
Көлен генә...
Мә ал, кызым! Зинһар, түгә күрмә!
Җан бөртегем минем!
Асыл затым!

## Улым белән кызыма

Сез минем күңел көзгесе.
Мәхәббәт җимешләрем.—
Шуңа Ходай камил иткән
Килбәтен-килешләрен.

Сез — минем йөзем аклыгы,
Карасы булмасын да.—
Каралыклар болай да күп
Өч көнлек дөньясында.

Сезгә таянасым килә
Иң олы терәк итеп,
Тоясым килә үземне
Сезгә гел кирәк итеп.

«Ике бөртек алтыным!» дип,
Горурланасым килә,
Дөньяда иң үрнәк әни
Булып каласым килә.

Сезне уйлаганда гына
Уңайга бара эшем.
Нәкъ шулай булалсам иде
Үзем дә сезнең өчен.

# *Кызыма*

Матур-матур төшләр күрә-күрә,
Бүленмичә, тәмләп йокла, кызым,
Синең өчен әле төннәр кыска,
Гомер шундый о-о-зы-ы-н!

Мин, төненә мең мәртәбә торып,
Юрганыңны төзәтермен, кызым.
Минем өчен инде гомер кыска,
Төннәр шундый о-о-зы-ы-н!

* * *

*Кызым Гөлназга 19 яшь*
*тулу уңаеннан*

Кызым минем!
Җирдә бөтен нәрсә кабатлана.
Таңнар туа һәр көн төн артыннан.
Кышлардан соң килә язлар, көзләр.
Сезгә килгән яшьлек үтте бездән.
Җирдә бөтен нәрсә кабатлана.
Кайгылар да була, шатлыгы да...
«Сөйгән ярым таптым!» — диеп сөенәсең.
Ялгышканың белеп — елый, көенәсең.
Җирдә бөтен нәрсә кабатлана.
Ләкин яшьлек кенә кире кайтмый.
Язмыш, диләр, балаларга күчә.
Мин сынадым инде әллә ничә.
Җирдә бөтен нәрсә кабатлана.
Бәхетләрем генә кабатла ла!
Бәхетсезлегемне кабатлама...

*20.07.97*

# Уйна, кызым

Күз яшемне чак-чак тыеп торам —
Килми бер дә, әй, сынатасым —
Уйный кызым, уйный пианинода
Бетховенның «Ай сонатасы»н.

Нәни бармаклары клавишларга
Тиеп кенә китә югыйсә,
Ә мин инде хыял диңгезенә
Чумып чыккан булам берничә.

Шул диңгезнең бәхет энҗеләрен
Бер җепкә тезәм дә уемда,
Тагам, бәхет юрап, еллар әле
Буразна салмаган муенына.

Кабат чумам энҗеләрне эзләп,—
Килә бәхетеңне озайтасым...
Тик син уйна гына, уйна, кызым,
Бетховенның «Ай сонатасы»н.

* * *

Балаларым! Ике канатым сез,
Авыр чакта сезгә таянам.
Ходай миңа сезне бүләк иткән,
Узмасын дип гомере заяга.

Бәһаләп булмаслык байлыгым сез,
Байлык кына түгел, терәк сез.
Әйтә алмыйм: «...Бу дөньяда сезгә
Мин генә,— дип,— никтер кирәксез».

Кирәкмен мин сезгә таянычка,
Тәмле ризык, киңәш-табышка,
Тормыш давылларын тидермичә,
Калкан булып алдан барышка;

Сезнең чыныкмаган иңегезне
Басмасынга дөнья гамьнәре,
Кара җаннар сезне каралтмаска,
Сулмасынга тормыш ямьнәре.

Кичерерсез, кайбер гамәлләрем
Сез дигәнчә килеп чыкмаса.—
Көчсез зат бит мин дә — хатын-кыз бит,—
Ә иңнәрне... авыр йөк баскан.

Мин түзәргә әзер барысына,
Әйткән гозеремне тотсагыз:
Кем булсагыз, кайда йөрсәгез дә,
Миннән әйбәтрәк булсагыз.

* * *

Без бу җирдә бары Мөслимнеке!
Шул мөслимлек белән көчле без.
Кеше хакын хаклый белгән өчен
Дөреслекнең үзе төсле без!

Без кемлекне җирдә әйткән чакта
Безнең өчен тыныч бул, Мөслим!
Горур килеш һәм гел данлы килеш
Яңгырар да торыр бу исем!

Без — мөслимнәр!
Димәк, чын кешеләр,
Җир кадерен белгән игенчеләр,
Җир шаулатып җырлап-биючеләр,
Ихлас елмаючы-көлүчеләр,
Янып-көеп сөя белүчеләр.
Түгел ләкин һич тә мескеннәр!
Чөнки без соң кемнәр? Мөслимнәр!

* * *

Мөслимемә кайтасым бар әле,
Урау юллар аша узасым бар.
Юкәләргә кулым сузасым бар,
Сердәшләрем итеп, йөрәктән.
Мөслимемә кайтасым бар әле,
Ык суларын иңләп йөзәсем бар.
Әрәмәдә җиләк өзәсем бар
Бөрлегәннәр белән беррәттән.
Мөслимемә кайтасым бар әле,
Әнкәемне тагын күрәсем бар.
Дусларыма сәлам бирәсем бар,
Кушып бетмәс йөрәк җылымны.

Мөслимемә кайтасым бар әле,
Сагына-сагына кабат китәсем бар,
Күрешүләр өмет итәсем бар.
Күреп мәңге туймас җиремне.

* * *

Әй, ак болыт! Кая синең юлың?
Борыл әле барган җиреңнән.
Сагынганда сиңа карап кына
Яшәп булмаганны мин беләм.

Барыр юлларыңны үзгәрт тә син,
Борыл әле, борыл Мөслимгә.
Туган туфрагымны коча-коча,
Ела әле минем өчен дә.

Ела әле, әйдә, бер туйганчы,
Садә яшьләремне күрсеннәр.
Бу кадәрле еламас та иде,
Чынлап сагына икән, дисеннәр.

Әй, ак болыт! Ашыкмачы, җаным,
Ачам сиңа тагын бер серем:
Мин кайчандыр өзелеп сөйгән ярны
Кочагында йөртә Мөслимем.

* * *

Сабантуйлар җитте, сабантуйлар!
Авылыма тарта мине уйлар.
Яулык-тастымаллар җыйганнардыр,
Чүлмәк, капчык барлап куйганнардыр.

Урамнардан үткәннәрдер инде
«Сабантуйга» диеп, җырлар сузып.
Мин шәһәрдә нишләп ятам әле?
Бара түгелме соң гомер узып?!

Газиз әнкәм, иртән иртүк торып,
Атна буе коймак пешергәндер;
Балалары белән чөкердәшеп
Узган гомерен исенә төшергәндер.

Барлагандыр күлмәк-яулыкларын —
Сабантуйга кия торганнарын.
Түр тәрәзәсеннән күзәткәндер,
«Кайтырлар...» дип, авыл урамнарын.

Искә төшергәндер, сабантуй дип,
Дүрт кызына күлмәк теккән чагын.
Күзләреннән ачы яшь тамгандыр,
Пычаклардай кыеп ялгыз җанын.

...Йа Ходаем, нинди сабырлыклар
Мине бу шәһәрдә тыеп тора?!
Юк! Ярамый! Кырык эшем ташлап,
Кайтып килим әле сабантуйга.

* * *

Мөслимемдә тагын сабан туе! —
Ык буенда узар быел да!
Һәр ел саен көздән, кышлардан ук
«Быел кайтырмын» дип җыенам.

Мөслимемдә тагын сабан туе!
Кайтып булыр микән, юк микән?
«Сагынып кайттым, Мөслимкәем!» — диеп
Әйтеп булыр микән, юк микән?

Мин кайтмасам, сабантуйларының
Булмас кебек кызык-ямьнәре,
Кайталмасам, үзем дәдер әле быел
Тыныч җәйли алмам җәйләрне.

Минем өчен яңа елның башы
Сабантуйларыннан башлана.
Мөслим сабан туен алмаштырып
Буламы соң инде башкага?!

Мөслим Мөслим инде! Үз-үзеңне
Әллә кемгә хет куй, хет куйма!..
Кем ничектер, белмим, әмма минем
Ярты җаным фәкать шушында!

Мөслимемдә тагын сабан туе!
Мин җыенып куйдым кыштан ук.
Кайтам булгач кайтам инде барыбер! —
Башка уйны җанга кушкан юк!

# *Мөслимдә сабантуйда*

Томырылып килә чабышкылар
Тоякта — ут, күзләрендә — ярсу!
Мин дә кайныйм кеше диңгезендә.
Кычкырышам: «Әйдә! Әйдә, Мансу-у-р!»

Кайсы җайдак исемедер, белмим.
Тик барыбер дәшәм өзелеп-өзелеп,
Җайдаккамы әллә хыялгамы:
— Әйдә, Мансур! Әйдә! Әйдә! — диеп.

Аптырашып тора ят агайлар
Алар белән бергә кычкырганга.
...Күпме генә өзелеп сөрән салма,
Мин чакырган кеше юк шул анда.

«Әйдә, Мансур!» — диеп, мин шул аңа
Хыялымда гына дәшә алам...
Сабантуйда кычкырсаң да килешә,
Барыбер ишеттерми гөжле мәйдан...

* * *

Әнисен күрүдән өмет өзеп,
Ятимләнеп беткән бала кебек,
Кайтып барган чакта Мөслимемә,
Юл буеннан ялгыз чәчәк өздем.
Өсте тузан гына! Исе менә!
Бәрелде дә килеп, җанымдагы
Иң газиз хисләрне уятты.
Аһ! Сагынылган Мөслим шулчаклы!
Сагынылган Мөслим. Эзләремне
Тугаеннан еллар юса юган.
Әрәмәдә кара карлыганнар

Сагышымны әнә саклап торган.
Сагынуларым җитеп бетми кебек,—
Ел тәүлегенә китәм йөз күреп.
Китәм имәннәргә яулык элеп,
Бирмәсен дип җанга тынгылык.
Сагыну ташсын, ташсын ургылып!
Мөслимемне гел искәртеп торсын,
Мәңге, мәңге онытмаслык булсын!
...Юл буеннан чәчәк өзә-өзә
Кайтып барам менә Мөслимемә!

* * *

Йөрим төнге Мөслим урамында,
Юкә исләренә исереп.
Үкенүләр катыш, сагыш катыш,
Бәхет катыш хисләр кичереп.

Йөрим төнге Мөслим урамында.
Һәрбер өе якын, үз миңа.
Бөтенләй икенче кеше булам
Ни өчендер, кайтсам шушында.

Ык ярына төшәм үрсәләнеп,
Суларында болыт шәүләсе...
Мөслимемдә генә каласы да,
Җәйләремне шунда җәйләсе...

Язмышларга сылтап була микән
Илең ташлап читкә китүне?
Кайтмас өчен түгел китүләрем,
Сагыныр өчен китәм мин сине...
Аһ, Мөслимем минем, Мөслимем!

* * *

Мөслимемә тагын кайттым әле —
Киткәнемә бер ай үтмәде.
Юкәләргә сары төсмер иңгән —
Бит очыннан көзләр үпкәнме?!

Йокымсырап киң басулар ята...
Җәйнең хатирәсе — эскертләр...
Хәтфә палас кебек яшел уҗым
Тирә-юньгә сихри төс керткән.

Уйлар камашырлык серле тынлык.
Ык сулары хәтта тын калган...
Сискәндермик, диеп, шул тынлыкны,
Әрәмәдә кошлар тукталган.

Кыр казлары киткән. Йорт казлары
Соңгы чирәм чемчи су буйлап...
Төнбоегы сулган күл янында
Басып торам мин дә уй уйлап...

Тау битенә сәйлән тезгән кебек —
Сарык көтүләре тупланган.
Үтәм дигән чакта сискәнепме,
Мөслимемдә көзләр тукталган...

* * *

Очып барам самолетта Мөслимемә,
Зарыгып кайткан очар кошлар төсле генә.
Томаннар эчендә калды Казан үзе.
Уйларымда, бар җанымда Мөслим бүген.
Очып барам самолетта Мөслимемә,
Шома юлдан атта чапкан төсле генә.
Ашкын хистән күңел никтер куйды уйнап,
Ничә китсәм, кире кайтам сиңа урап.
Очып барам самолетта Мөслимемә,
Ә Мөслимем чиккән яулык төсле генә,
Аллы-гөлле төсләр белән бизәкләнгән,
Сагыну саркып чыкты кинәт үзәкләрдән.
Очып барам самолетта Мөслимемә,
Кочар идем газиз әнкәм төсле генә,
Сыйса әгәр кочагыма туган җирем,
Җан дәвасы, тән дәвасы син, Мөслимем!

* * *

Мөслимдә төн, ай-һай, кыска икән,
Күз ачып йомганчы узып киткән.
Бәхет диңгезендә йөзүләрем
Өн идеме әллә төшем микән?!

Мөслимдә көн, ай-һай, озын икән:
Көн кызумы, йөрәк кузым микән?
Көне буе сине көтүләре
Сабырлар җитмәслек сузым икән.

Озын көннәр кирәк булмаган күк,
Кыска төн дә кирәк түгел икән.—
Көн белән төн буталышса гына
Шундый рәхәт, шундый җиңел икән.

* * *

Әй, садә җил! Канатланып кил дә
Урап уз сабантуй мәйданын.
Батырларның йөрәкләре кыза,
Баса алмый каны кайнавын.

Әй, садә җил! Дулкынланып кил дә
Сыйпа чәчләреннән Илбашын*.
Халык гамен икърар кылган чакта
Зиһененә аклык уралсын!

Әй, садә җил! Узам, диеп килмә,
Калам, диеп кил син Мөслимгә.
Тырыш халкым ярсып эшләгәндә
Дәрт бирергә синең көч кирәк.

Әй, садә җил, очып кына кил дә
Мәйдан уртасына уз син дә.
Бәйрәм бүген, изге бәйрәм бүген —
Сабан туе бүген Мөслимдә!

*05.06.99*

---

* Мөслим сабан туена Президентыбыз Минтимер Шәймиев кайткан иде.

* * *

*Рөстәм Мирзагали улы Шәриповка*

Үз туфрагында туып үскән егет,
Шушы җирдә буын ныгыткан!
Кайсы җирдән куәт алганыңны
Як хуҗасы, берүк онытма!

Ык куәте сине көчле итәр,
Булсаң да син илдә кем генә!
Ык куәтен, Мөслим кодрәтен мин
Телим бүген синең илләңдә.

Кешелегең белән син көчлесең,
Һәркем шулай көтсен иллесен.
Син көчлесең, чөнки Мөслимле син,
Сөеп туймас туган илле син!

*30.12.99*

# *Казан — Мөслим юлы*

Кичкырынлап яңгыр явып үткән,
Алмаларның битен чылатып.
Көздән бераз алда өлгерим, дип,
Мөслимемә барам мин кайтып.
«Ничек безнең күлмәк?» — дигән кебек,
Көязләнеп тора усаклар.
Кошлар тынган, нәфис гөлләр сулган,
Яфрак коелмаган берчаклар.
Кара толым булып, басуларда
Сөргән җирләр кала сузылып.
...Әле бетмәс, диеп яшәгәндә,
Җәйләрне дә киткән узылып.
Хәзер безнең чират, дигән кебек,

Чикләвекләр тулып өлгергән.
Ә без тулганбызмы, сулганбызмы? —
Дөрес җавапларын кем белгән?
Тол хатыннар кебек моңаешып
Басып калды ялгыз каеннар...
Минем әле, толлыгымны онытып,
Күкрәп-яшьнәп алыр җаем бар.
Без дә әле көлмәк күрсәтергә
Чыгып баскан усак мәлендә.
Калырбыздыр берчак агачыннан
Аерылган яфрак хәлендә.
Аһ! Гомернең аттай чапкан мәлен
Торып булса иде туктатып.
...Бәлки әле, күреп калырмын, дип,
Мөслимемә барам мин кайтып...

*31.09.96*



## II

*Бөтен кеше аңлар, дип ышанмыйм —*
*Кемдер аңлар, кемдер аңламас...*
*Гаепләрләр. Беләм. Тик шулай да*
*Күңелдәген әйтми ярамас!*

# *Тимәгез сез миңа*

(*Бераз шаярып*)

Тимәгез сез миңа! Гел үземчә
Булыйм әле бүген аз гына.
Кырыслыкка күнеп барам ласа,
Җанымда булса да наз гына.

Тимәгез сез миңа! Хисләремне
Шәрран ярып ачып җибәрим.
Язылмаган кануннарга табынып
Күп яшәдем инде җирдә мин...

Тимәгез сез миңа! Бүгенгедәй
Мин иртәгә, бәлкем, булалмам;
Үзем чагым бүтән беркайчан да
Күралмассыз. Мин дә күралмам...

Тимәгез сез миңа! Бәлкем, мине
Гел икенче яктан ачарсыз.
Бүген тимәгезче, зинһар өчен!
Иртәгәдән тия башларсыз...

* * *

Кемдер ансат кына мөлкәт җыеп,
Бәйрәм ясап ята аяк тибеп.
Бу дөньяда язмагандыр, ахры,
Яшәүләре безгә рәхәт күреп.
Аh, җаный, ваh, җаный,
Бу дөньялар ник фани?

Кемнәргәдер, сорамасалар да,
Бирә Ходай бәхет өеп-өеп.
Безнең гомер гел алданып үтте
Һәр бәхетсезлекне бәхет диеп.
Аh, җаный, ваh, җаный,
Бу бәхетләр ник фани?

Кемдер хәйлә белән кияү таба,
Без тилмергән булдык ярлар сөеп.—
Җанны телгән әрнү-газапларны
Алданганбыз икән сөю диеп.
Аh, җаный, ваh, җаный,
Бу сөюләр ник фани?

Йөргән булдык намус дигән булып,
Тишекләрне ямап, ертык тегеп.
Гомер аты ыргып үтте яннан —
Борылыштан гына калдык күреп...
Аh, җаный, ваh, җаный,
Бу гомерләр ник фани?!

* * *

Йа Ходаем, нинди замана бу?! —
Ярап булмый кемгә ничек кенә.
Надан, икейөзле, ялагайлар,
Ришвәтчеләр генә шәп көн күрә.

Йа Ходаем, нинди замана бу?! —
Белми ата улны, ана — кызны.
Үзеңдә булмаса, күршеләрең
Биреп торыр, димә, ипи-тозны.

Йа Ходаем, нинди замана бу?! —
Яшәп булмый һич тә намус белән...
Болай озак дәвам итә алмас,
Ахыры булыр тиздән — шуны беләм...

* * *

...Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса үзем үзгәрәм...

*Разил Вәлиев*

Бик сәер заманда яшибез.
Үзгәрә... үзгәрә кешеләр.
Кемнәрдер бер тәүлек эчендә
Бихисап үзгәрү кичерә.
Андыйлар мактана чамасыз:
«Мин,— диеп,— үзгәрдем! Тизләндем!»
Ышанмыйм! Бик алай тиз генә
Үзгәрми шул кеше дигәнең.
Күңеле үзгәрми. Үзгәрсә
Үзгәрә торгандыр битлеге —
Гавәмнәр янында — бертөрле,
Түрәләр янында — бертөрле.

Әйтәлмим кушылып аларга:
«Үзгәрдем, тизләндем мин дә...» — дип,
Бер акыл утырткач, тиз генә
Булмый шул, булмый ул үзгәреп.
Әнкәем мине бу дөньяга
Китергән биреп саф акылын.
Дөньяга яраклы булыйм, дип,
Үзгәрмәм, үзгәрмәм, ахры.
«Үзгәрдем...» дигәнгә ияреп,
Һич базмам сафсата сатарга! —
Җитәрмен барып мин ахырга
Тумыштан бирелгән акылда!

* * *

Мине гомер буе орышалар...
Бу хәл килә туа-тумыштан.
Кемнәр белә: бәлкем, фани дөнья
Тора булыр үзе орыштан.
Күңелемдә бер бөртек тә кара
Булмаган өченме тиргәләм...
Орышлардан туңган күңелемне
Язмыш җилләрендә җилгәрәм.
Ни гаҗәптер — күпме орышылып та,
Орышырга булмый өйрәнеп.
Шыр гаепле сыман басып торам,
Орыш иясеннән җирәнеп.
Бигайбә, дип, гаебемне таныйм,
Көчсезмен мин орыш алдында.
Нихәл итим: андый галәмәтнең
Әсәре булмагач канымда.
...Шулай яши-яши күнегелгән
Орышлардан торган тормышка;
Кешелегем сытып-изәр өчен
Орышлардан җәтмә кормышка...

Бер көн килеп...
Йөрәгемне күкрәк читлегеннән
Умырып алыр шушы җәтмәгез...

Күңелкәе тулмасын, дисәгез,
Миңа йомшак сүзләр әйтмәгез.

* * *

Бер генә дә кылган гамәлебез
Булмады шул безнең кешечә.
«Кеше төсле» булмау аркасында
Казындык без һаман «чүплектә».
Беләм: безнең ушбу хаталыклар
Анадан туyга башланды.
Үзгәреп булмый шул берничек тә,
Ташларга орсаң да башларны.
Яратмыйча яши алмыйм, диеп,
Пүчтәк ярлар сөеп интектек;
Безне алиһәдәй күргәннәрне
«Яратмыйм»нар белән кимсеттек.
«Яратмыйм»га «ярамый» өстәлде,—
Ир хатыны булып алдангач,
Изгелегең өчен таш атуга
Хыянәтләр килеп ялгангач.
Шул «Ярамый!» башка җитте безнең,
Илле яшькә китереп «терәде».
«Кеше төсле түгел» газиз башның
Юк әле бер рәхәт күргәне.
Кеше унҗидедә белгәннәрне
Илле «якасында» беләбез.—
«Сакаллы сабый» көненә калдык,
Ахры, менә шуңа күрә без.
«Миңа барысы да соңлап килә...»

Дигәннәре безгә «тач» кына.
Соңлап кергән шушы акылларны
Сыйдырып бетерсен баш кына.
Әмма күпме акыл утыртсак та,
«Кеше төсле», ахры, булмабыз:
Фәхеш, ялган, хөсетлек алдында
Билне бөгеп, башны ормабыз.—
Чөнки бу дөньяга яраклашып,
Анабыздан кабат тумабыз.

* * *

Газиз туган телем аһәңнәре
Канга, җанга сеңгән тумыштан.
Кеше диеп мине санамагыз,
Тапкан анам телен онытсам.

Бара-бара барып чыктык, ләгыйнь,
Тукайны укыйбыз урыстан.
Татармын мин, димә, газиз балаң
Бөек Тукай телен онытса.

Ояты ни: татар балалары
Урыс булып туа тумыштан;
Үз телеңне үзең акламасаң,
Үз телеңне үзең сакламасаң,
Рәхим-шәфкать көтмә язмыштан!

# *Кайтма, Тукай!*

Кайтсаң иде, Тукай, күрер идең
Милләтеңнең үсеш юлларын.
Ишетер идең, ишетеп сөенер идең
Елмаюын илнең, җырларын.

*К.Булатова*

Кайт та, кайт, дип чакыралар сине,
Кайта күрмә, Тукай, үкенерсең.
Милләтеңнең «үсеш юлы»н күреп,
— Тфү, ләгыйнь! — дип төкерерсең.
Хәзер инде заманалар башка,
Танымаслык булып «үсте» татар —
«Өлкән агай» башыннан сыйпаса,
Телен түгел, хәтта үзен сатар.
Рәхмәт яусын, файдасы күп тиде.
Җитмеш елдан артык «хөррият»нең —
Урыс теле аша барып ирешә
Татар баласына шигърияте.
Кайтсаң, чынлап хәйран калыр идең
Милләтеңнең «үсеш юллары»на:
Финляндия кәгазь биреп тора
«Салават күпере»н чыгарырга.
«Идел» журналына рөхсәт алдык
Егерме генә ел сорый-сорый.
Татарга игътибар арта төште,
Укучылар гына табып булмый.
Урыс, үзбәк, башкорт, әрмән «чүпли»
Туташларның алма кебекләрен,
Катнаш никахлар «суырып йотты»
Менә дигән татар егетләрен.
Гомер буе эшчән татар халкын
«Бөек төзелешләр» дәшеп тора.
Ә татарга «эшче көчләр» бирә
Белоруссия һәм Украина.

Черек кулләр күптән череп бетте,
Елгаларның суын сасытабыз;
Диңгезләрне киптерү буенча
Бөтен Җир шарында дан тотабыз.
Сәүдә итә белә Русия —
Чит илләргә нефть, газны сата.
Газ факелларына сәҗдә кылып,
Гүр иясе булды күпме картлар.
Авыл агаеның башын җылыта
Малаеннан калган «мескен» бүрек,
Чит ил дамалары «мәйдан тота»
Безнең мехтан теккән туннар киеп.
«Коммунизмга!» дип бара-бара,
Тарих чүплегенә чыктык килеп.
Капитализмның «эче ката»,
Безнең «бөек үсеш» юлын күреп.
Түрәләрдән ярдәм сорый-сорый,
Туфли табаннары кубып төште.
Исән калган юкәләрне каерып,
Чабата үрергә вакыт җитте.
Менә шулай тел, лөгатьне «сатып»,
«Иңне иңгә терәп» көн итәбез.
Рок, секс, СПИДлар «астында»
«Гөлҗамал», «Зиләйлүк», «Әпипә»без.
Нигә кайтканыңа үкенерсең,
Чакыралар дип, берүк кайта күрмә!
«Үсәбез!» дип, корып беткән өчен
Синең алда оят булыр безгә!

*12 март, 1990*
*Малеевка*

* * *

Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,
Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам.

*Г.Тукай*

Кемдер әйтер, бәлкем: «Нигә Пушкин?
Тукаеңны кирәк белергә!
Нигә диеп әле шул урыска
Тәлинкә тотарга гомергә...»
Шөкер, Тукай мәңге минем белән,—
Бала чактан «су кебек эчтем».
Кырлай аша Мәскәү, Питерларга,
Тукай аша Пушкинга күчтем.
Пушкин шигырьләрен ятлап йөрдем —
Мәктәп яки әни куштымы?!
Инде менә «үз белдегем белән»
Яңадан өйрәнәм Пушкинны.
Пушкин аша мин урысны таныйм,
Бөеклеген аңлыйм татарның.
Тукаеңның кадерен аңлар өчен
Пушкиннарны белү начармы?!
«Урысныкы», «татарныкы» диеп,
Бүлешеп ятудан ни файда?!
Әгәр исән булса, нәкъ шулай ук
Әйткән булыр иде Тукай да!
Тезләнгәндә Тәңре каршысына
Татар мәңге исән булсынга —
Тукаема сәҗдә кылам бүген
Һәм баш иям бөек Пушкинга.

* * *

«Дуслар» димсез?! Дуслар — менә дигән!
Андый дуслар, әлбәт, сирәк лә.
Бер — алдымда, биш — артымда алар
Үзләренә нидер кирәктә.

Туганнармы? Әйбәт туганнарым!
Андыйлар юк. Булса — сирәк лә.
Көненә ун килеп «хәл» беләләр
Үзләренә нидер кирәктә.

Ир-атлармы? Дөнья тулы алар!
Тик чыннары гына сирәк лә.
«Яратам» дип үзәгеңә үтә
Үзләренә нидер кирәктә.

Дус, туган, ирләрнең берсе дә юк
Сиңа кайчак нидер кирәктә...

## *Кырыкныкы — шырыкта...*

(*Ярым шаяру*)

Буласылар булган инде,
Бетәр нәрсәләр беткән;
Унҗидедәге күңелгә
Кырык та килеп җиткән.
Кара шомырт чәчләремдә
Ак төсләр хаким итә.
Уңышы җыеп алынган
Җанымны җилләр кисә.
Яшьлек үткән... Сөю киткән...
Кырыкныкы — шырыкта...—
Шырпы сызар кешесе юк! —

Дөрләп янарга утта!
«Минем хәлгә төшкән бу!!!» — дип
Көлеп торасың. Беләм!
Һи!!! Мин әле Яшәү дигәннең
Татларын яңа сизәм!
Җитә көчем иярләргә
Иң гаярен ир-атның! —
Мин бит сабыр сандыгымның
Ачкычларын югалттым!
Дилбегәсен ычкындырдым
Гомерем чаптарының.
Их! Тоеп кал ләззәтләрен
Иң назлы чакларымның.
Айкал-чайкал суларында
Сөюем дәрьясының!
Кырык утта дөрләтермен! —
Чыдаса кан басымың!
Йөрәгеңә кырык төрле
Төендәй төйнәлермен! —
Үчен алырмын сөюсез
Үткәргән көннәремнең!
Сагынырсың, саргаерсың,
Өзелерсең мин юкта,—
«Кырыктагысыз яшәүләр
илтә,— диеп,— шырыкка!»

# Ышанма син кешеләргә

Ышанма син кешеләргә —
Хәлең сораган булыр,
Моң-зарыңны күңел салып
Хәтта тыңлаган булыр,
Кушылып елар яшеңә,
Аркаңнан кагып алыр,
Күңелеңне эретерлек
Төче сүз табып алыр.
Күп тә үтмәс, серләреңне
Чәчәр бөтен ил буйлап.
Күпертер һәрбер сүзеңне,
Үзенчә кисеп-турап.
Иң мөкатдәс күңел серең
Каралып беткән булыр,
Йөз гайбәтче авызыннан
Мең кабат үткән булыр.
Бу хәлләргә хәйран калып,
Еларсың син көн-төнен.
Ышанма син кешеләргә,
Ачма, дустым, эч сереңне.
Йөрәгеңдә сагыш булса,
Кайгы басса күңелеңне,
Үзеңә сереңне бушат та
Юат син үз-үзеңне.
«Билдән түбән үзеңә дә
Ышанма...» дигән сүзнең
Изге сабак икәнлеген
Аңларсың шулай үзең...

* * *

Югарыга карап фикер ит,
Түбәнгә карап шөкер ит.

*Халык сүзе*

Нәрсә күрдем соң мин бу тормышта?—
Дүрт кешегә — унҗиде квадрат...
Өстәл, телевизор, пианино,
Ике якта — ике караваt...

Күрше бүлмәдәге исерек татар
Төне буе «җыелыш үткәрә».—
Йә Пушкиннан шигырь сөйләтә ул,
Йә «Совет паспорты»н күтәрә.

Коридорга чыгып: «Мин — хозяин!
Сез — килмешәк!» — диеп акыра...
Өченче бүлмәдә рус карчыгы
Алласына табынып аһ ора...

Ярты төндә «эштән» кайткан ирнең
Хәбәре юк безнең хәлләрдән.—
Үлеп йоклый...— Берәр тол хатынны
Артыграк, ахры, «җәлләгән».

...Ә мин әкият сөйлим куркуыннан
Йокысы качкан балаларыма...—
Язылась шигырем дә алар,
Укылмаган романым да...

* * *

Мин яраттым сине
Җаным-тәнем белән.
Яныл-көеп. Дөрләп. Ут кабып.
Ләкин синең саран күңелеңдә
Кабынмады җавап учагы.

Син сындырдың
Ике канатымны...
Мин егылдым. Хәлсез. Әлсерәп.
Суга гына белгән ике кулың
Йөрәгемә үреләләр ... җан сорап.

* * *

Синсез генә яшәп карыйм әле,—
Бәлкем, рәхәт булыр.
Ватык арба кебек тибә йөрәк —
Шалдыр-шолдыр...
(Синең мәхәббәттән калган «бүләк»
Бары шулдыр...)
Башка берни дә юк. Җанда бушлык,—
Уңышы җыелган бакча кебек.
Иң кирәк чакта да булмый елап...
Булмый көлеп...
Сыкы койды чәчнең карасына
Гомер бураннары.
Тәрәзәсе ватык. Уты сүнгән...—
Күңелем урамнары.
Борылышка җиткәч, чыгымчылап,
Типте язмыш аты —
Салулап барды да... атты болгап
Гомерем арбасы.—

Барып төштем, челпәрәмә килеп,
Чүплек өеменә...
Кара җаның күләгәсе кунды
Ап-ак күңелемә...

* * *

*Розага*

«Кияүгә чык,— дисең.— Син әле яшь.
Хәтта бала табып өлгерерсең...»
Рәхмәт, дустым... Табып тормам инде...
Кырык дүрттә... Кеше көлдерерсең.

«Ничек инде,— дисең,— ятмак кирәк
Шул яшеңнән ирсез... Мендәр кочып...»
Ялгыз булмыйм диеп, ятыйммыни
Кеше ире белән качып-посып...

Сүзең дөрес. Озын төннәр буе
Ялгыз мендәремне кочып ятам.
Ходайга мең шөкер — мин бит әле
Уты янып торган өйгә кайтам.

Һәр кич саен ишегемне ачып,
Улым белән кызым каршы ала.
Шул бәхеттән мәхрүм итмәсәң лә
Газзә вә җәлләһи газыйм* Алла!

* Чиксез зур бөеклек иясе дигән мәгънәдә.

* * *

Юлда туңып, хәлдән таеп,
Сөрлегеп калсаң,
Инде беттем, дигәч кенә
Ят йортка тарсаң,
Алдын-артын, ни булырын
Барлап тормыйсың,
Катып үләсе килми бит,
Керми нишлисең?!
Һәм, керүгә, кочаклыйсың
Чит кеше мичен.
Исәп синең җылытырга
Аяк-кулыңны.
Ләкин... Чит мичкә терисең
Йөрәк турыңны.
Йөрәк җылынса, җылына
Аяк-кулың да.
Өшү башлана шул никтер
Йөрәк туңудан.
Тәнең туңса, җитәр җылы
Синең өченгә
Сөялеп бер җылыну да
Кеше миченә.
Җаның туңса, аһ, дусларым,
Нишләмәк кирәк?!
Була алмый, була алмый
Чит мичләр терәк...
Җылытырга җанкаеңны
Үз мичең кирәк.
Туңа җаным, өши җаным...
Туңса, нишлисең?
Үз мичем булалмассың шул
Син минем өчен...

# *Килгән идем җиргә...*

Не любовницей — любимицей
Я пришла на землю нежную...

*М.Цветаева*

Сөяркә булырга түгел, сөелергә
Килгән идем җиргә.
Гомер кояшыбыз баеганны
Каршыларга бергә.
Исәп иде мине иркәләгән
Кулларыңны үбеп,
Гомер итү җаның олпатына
Тезләремне чүгеп.
Исәп иде карау бу дөньяга
Синең күзләр белән,
Нахак карасыннан агарырга
Синең сүзләр белән.
Исәп иде төн йокымны бүлеп,
Иреннәрең тәмен тәмләп кенә
Гомер итү уф-зарларсыз. Дөнья
Ямен ямьләп кенә.
...Нишлисең бит! Сөелүләр түгел,
Сөяркәлек насыйп...
Яратабыз... «Ярлыкагыл!..» — диеп,
Кешеләрдән качып...

* * *

Минем бу дөньяда барлыгымны,
Берлегемне белеп торасың;—
Таныш кебек йөзләр очрый калса,
Кинәт йөзең читкә борасың.

Әйтерсең лә син мине белмисең
Һәм беркайчан белмәгәнсең дә;—
Бар хәсрәтең: гайбәт таралмасын,
Безнең турыда сөйләмәсеннәр.

Аһ! Нишлим соң?! Гомер уртасында
Сине табып, кабат ялгыштым.—
Язмышымның алмасы ачы дип,
Кеше алмасына ябыштым.

...Ачы була икән, бигрәк ачы
Чит бакчаның төче алмасы.
Хак Тәгалә, корт баскан булса да,
Үз алмаңны тартып алмасын.

* * *

Син кемнеңдер иркә кочагында
Сырпаланып, изрәп яткан чакта,
Мендәремә ялгыз башым салып,
Өзелеп-өзелеп уйлыйм синең хакта.

Урамнарда сыенышып узган
Парлы-парлыларны күргән чакта,
«Ялгызлыклар — безгә канат...» — диеп,
Өзелеп-өзелеп уйлыйм синең хакта.

Сөюләргә сусап, исемеңне
Бар дөньяга сөрәнләрлек чакта,
Бер Ходайдан сабырлыклар сорыйм —
Кешеләргә сөйләп ялгышмаска...

* * *

Басып торам Очлы тау башында,
Киң галәмне күземә каратып.
Сине яратканга Зәй суларын,
Тайсуганны өзелеп яратып.

Нигә шулай яратылган дөнья?—
Яшәү кадере тауда беленә.
Күңелеңне кочып алыр булып,
Мин текәлеп карыйм күзеңә.

Аста тирән упкын! Хәтта уйлар
Чәлпәрәмә килә, карасаң.
Ишетсеннәр таулар, ак болытлар —
Мин яратам сине! Я-ра-там-м-м!

Хисне тыя алмый «ярамый»лар! —
Кочагыңа килә ыргыйсы!
Бар җиһанны күкрәгемә кысып,
Сиңа атап җырлар җырлыйсы!

Һәм — яшисе килә! Бик яшисе!
Бары синең белән, әлбәттә!
...Мин бәхетле булып алам шулай —
Тайсуганга кайткач. Әлмәттә...

* * *

Иртән торам. Ашыйм. Йөрим. Сөйлим. Йоклыйм.
Гәүдәм тере. Җаным — юк бугай...
Кеше килә. Китә.
Кояш чыга. Бата.
Иртәләрен шулай. Кич шулай.
Сабак алып шундый булмадым мин.
Бу халәтем — туа-тумыштан.
Яратмыйча яши алмам мәңге —
Бирәү кирәк минем тормышка.
Бирәү кирәк.
Бары бирәү генә
Күңелемә минем баксачы.
Бары сөя белсен. Өзелеп сөя,
Кирәк түгел даны. Акчасы.
Тәмле аш пешереп каршы алыйм.
Күлмәкләрен юыйм арсам да.
Аның барын тойыйм, мәхәббәтен —
Юлда булсам, өйгә кайтсам да.
Ул да бары сөеп, сөеп кенә
Күзләремә минем карасын.
Кеше күрә. Күрми.
Дөнья белә. Белми.

Мәңге яратырга ярасын.
Килә янәшәдән барасым.
Аерым-аеры, качып-посып түгел,
Илдә-мирдә — мәңге янәшә!
Документсыз, никахларсыз гына
Ходай үзе безне ярәшкән.
...Җирдә яшәү — мәгънәсез бер шөгыль. —
Дөрләп янмый, өзелеп сөймичә.
Җирдән бик тиз генә китә алмам,
Соңгы йөрәк кузым сүнмичә.
«Сөеп үләм инде...» — димичә.

## *Балаларыма васыять урынына*

...Үлә калсам, артык еглап
Күзең бетермә, балам.—
Сезнең белән Җиде күктә
Очрашу көтеп калам.

Җисмегез белән исемем
Гел агартып торыгыз,
Васыятем: ни кылсагыз да,
Миннән әйбәт булыгыз!

Түгел булса, тыныч кына
Ятып булмас оҗмахта,—
Теңкәгезгә тиярмен мин
Көн дә кайтып кунакка.

* * *

«Сөям» дә «сөймим» диеп,
Һич башың авырттырма.
Сөйми-сөелми яшәүләр
Ошады әле миңа.

«Ярым» да «ярым» диеп,
Ашаудан каласы юк.
Төн белән көнне бутап,
Йокыдан язасы юк.

Сөюдән бизмәсен, диеп,
Көн-төн баш ватасы юк.
Тәненә тәнеңне терәп,
Җан атып ятасы юк.

Бер-береңне аңламыйча,
Кайнар яшь коясы юк.
Исемен җуелмаслык итеп
Җаныңа уясы юк.

Ят та йокла, тор да уйна.
Уйна да көл, сөймә яр.
...Дөньяда болай яшәүнең
Йә, әйт, ни кызыгы бар?

* * *

Аерылышкач, зари-зари,
Күз яшьләрем коймадым.—
Алтын яшем әрәм итәр
Син түгел, дип уйладым.

Уйларымнан уела-уела,
Йокысыз төн узмадым.—
Төннәремне зая итәр
Син түгел, дип уйладым.

Ялгышылды. Хаталардан
Бер мин хали булмамын.—
Абынып сөйдем. Табынып сөяр
Син түгел, дип уйладым.

«Соңгысы!» — дип, үз-үземә
Тәүбә итеп тормадым. —
Без табынып сөяр ярлар
Тагын бар, дип уйладым.

* * *

Йөгергән булдым гел алга,
Абынып та сөртенеп.
Артыма борылып карыйм да
Куям авыр көрсенеп.

Нигә кирәк булган, димен,
Үрелергә түбәнгә.—
Мәртәбәләргә тезләнеп,
Кирәк булган үрләргә.

Гомер буе интегелгән
Намус саклап, тир түгеп;
Игелек өчен игелек
Ходайдан гына күреп.

Инде акыл алдык бугай
Гыйбрәтләр күрә-күрә.
Барыбер һаман үзебезчә
Яшәрбез шуңа күрә.

* * *

Урманнарда йөрдем берьялгызым,—
Таянырга таяклар тапмадым.
Барыр җирләремә җитә алмам —
Ярты юлда тугардым атларым.

Дөнья буйлап йөрдем берьялгызым,—
Таянырлык кешеләр тапмадым.
Иңнәремне баскач дөнья гаме —
Ярты юлда туктадгалган чакларым.

Урманда да — ялгыз, дөньяда да,—
Өлешемә тигән көмешләрем.
Җирдә ике гомер яшәсәм дә,
Башка язмыш белән килешмәмен!

* * *

Кара инде бу дөньяны, җаным!
Карасана, нәрсә кылана!
Элеп ала, селкепләр лә сала —
Әйтерсең йомычка син аңа!

Кара инде бу дөньяны, җаным!
Калмады бит бер дә рәте.
«Яши белсәң — менә дигән!» диеп,
Кайчан соң, алдалап, кем әйтте?!

Кара инде бу дөньяны, җаным!
Китәр кебек беркөн таралып.
...Мин дә кайныйм дөнья казанында,
Көннән-көн ныграк каралып...

## III

*«Мәхәббәт язларга тиң...» — дип,*
*Кемнәр әйткән, ни сәбәп? —*
*Сагышыннан җан саргайган*
*Сары көз ул — мәхәббәт...*

* * *

Аңладым, дип, бу дөньяны,
Мең мәртәбә алдандым.
Алдандым да, сүнеп беткәч,
Кабат тагын җанландым.
Асыл агач дип, агачның
Черегенә асылдым.
Ашым өчен арттан аткан
Таш астында басылдым.
Дөньяның бар алдауларын
Ялгыз башым күтәрдем.
Бүтән алданмам дип, кабат
Алданганга үртәлдем.
Күңелемне таптап үткән
Табаннардан каралдым...
Инде беттем дигәч кенә,
Сине табып алдандым.
...Син нәтиҗәсе Ходайга
Буйсынып ялваруның.—
Бусы инде гомеремдә
Иң соңгы алдануым!

* * *

Тәрәзәдән карап утырам мин...
Урамнарда карлар төшкән чак.
Казан халкы, кемнәрнедер тиргәп,
Тукталышта трамвай көткән чак.
Кулларына сумка-биштәр асып,
Кибетләрдән әйбер җыяр чак.
Авыл халкы, бер-береннән узып,
Ашка йөрер, сугым суяр чак.
Арба чоры үткән, чана җикмәс,
Барыр җиргә җәяү китәр чак.

Кияүлеләр ирләрен каргаган,
Кияүсезләр кияү көтәр чак.
Кашкарыйлар, чәчәк коялмыйча,
Вакытыннан алда шиңгән чак.
«Яратуның кадерен беләм мин!» — дип,
Син ашкынып миңа килгән чак...
Тәрәзәдән карап утырам мин...

* * *

«Язларында ялгыз йөрсәң,
Йөрәкләр яна инде...» — дип
Җырлама миңа, җаным!
Минем менә күзләрдә дә
Йөрәкләр янган чагым.

Сары яфраклар санынча
Уйлар уйлаган чагым:
Яфраксыз агачлар кебек,
Шәп-шәрә калды җаным...

«Мәхәббәт — язларга тиң...» — дип,
Кемнәр әйткән, ни сәбәп?—
Сагышыннан җан саргайган
Сары күз ул — мәхәббәт...

* * *

Челлә җирнең тамырларын өткәч,
Соңгы күз яңгыры килеп ята...

*Зөлфәт*

Минем гомер гел челләдән торды,
Яңгырлар күрәлми тилмердем.
Шуңадыр да ... чәчәк аталмыйча,
Корыды гөлләре күңелнең.
Юкса алар шау бөредә иде,
Беркемдә дә андый юк иде.
Ата калса әгәр, фани дөнья
Гүзәллеккә тулырлык иде.
Гомерем буе шуңа су сорадым,
Сулмасын, дип, күңел гөлләрем.
Бер тамчы су беркем бирмәячәк
Икәнлеген, ай ла, белмәдем.
Чәчәк кенә түгел, гөлләремнең
Тамырлары хәтта корыды...
...Күзләр җиткәч, бер уч су тутырып,
«Сиңа!» — диеп суздың кулыңны.
Мин йотылып эчтем... онытылып...—
Бер тамчысы хәтта калмады. —
Сусауларым тик көчәйде генә,
Басылмады йөрәк янганы.
...Инде корып беткән гөлләремне
Бер уч суың гына терелтмәс...
Һәм... ышанмас күңел яз килергә...
Күзләренә инде күнеккәч...

* * *

Сыздырып ла гармун уйнап узды,
Сискәндереп төнге йокымны.
Йөгерепләр чыгып сорар идем:
«Сөюләрең,— диеп,— шушымы?!»

Гармун телләренә баскан саен
Йөрәгемә күчте сагыш-моң.
Кавышу сәбәпләрен уйлый-уйлый,
Сарыларга, ахры, сабыштым.

Уйнап узар микән шулай тагын,
Кара төнгә сихри моң сирпеп?
Яшәтерме мине гомерем буе
Сөю хисләренә исертеп?!

* * *

«Аһ» дисәм дә, «уһ» дисәм дә,
Җиңел түгел, авыр хәлем.
Гомеремнең берьялгызы
Юл чатында калган мәле.

Җиңел түгел тутыруы
Гомер буе бушатканны...
Сөю эстәп ярсуларым
Хәзер микән, шул чактанмы?

Җилгә каршы сөрән салып,
Килә ярсып кычкырасым:
— Мин барасы юлга чык! — дип.—
Нигә карап тик торасың?!

Күрмисеңме: күзләремдә
Соңгы сөю уты дөрли...
Шул утларда көйри-көйри,
Ничек яшим сине күрми?!

Килә әле, килә минем
Соңгы кабат сөеләсем!!!
Ә аннары... сүнәрменме?
Дөрләрменме?! — Син беләсең...
Син беләсең!!!

* * *

Көндез кояш кирәк булса,
Ак ай кирәк киченгә.
Ай белән кояш тик кирәк,
Бәгърем, минем өченгә.

Бер елата, бер көлдерә,
Бердән сагыш эчерә. —
Житмеш жиде хәлгә кертә
Якты көннең эчендә.

Жаным теләп утка сала,
Дәрья суга төшерә. —
Бер карасаң — яшәтә ул,
Бер карасаң — «үтерә».

Чыгымчы ат кебек дулап,
«Тәртәгә тибә» йөрәк.
Кемгә ничектер, әйталмыйм,
Ә миңа шулай кирәк.

* * *

Гомер буе җыйган серләремне
Сөйлисе дә әле сөйлисе.
Без бит синең белән бер-беребезгә
Каш астында ике күз төсле.

Битәрләмә «миңа кадәр,— диеп,—
Сөючеләр сине күп булган».
Сине күргән мәлдән алар барысы
Булмаган да кебек юк булган.

Мин үзем дә синең тормышыңда
Иң беренчең түгел анысы...
Була алсам иде моннан ары
Бердәнбере һәм дә... соңгысы.

* * *

Бүген таңда мине сискәндереп
Ялгыз торна тавышы уятты.
Җанымны өшетте ялгыз тавыш,
Әллә нинди уйлар уйлатты.

Көз бит инде. Көзгә җиткәч кенә
Берьялгызың калу авырдыр.
Ялгызларның сабыр канатына
Сары сагыш җиле кагылыр.

Җәйләрендә алар пар булгандыр,
Белмәгәндер ялгыз каласын.
Ялгыз торна язмышына дучар
Нигә кайбер адәм баласы?

...Мин сыенам җылы кочагыңа.
Рәхәт анда. Туңмыйм салкында.
...Җанны кисә уем — иртәгәсен
Ялгыз калачагым хакында.

* * *

Син йоклыйсың, бәгырькәем, изрәп,
Ә мин сиңа карап утырам.
Сиңа гына мәгълүм төш илеңне
Изгелекләр белән тутырам.

Төшләреңдә, бәлкем, кермимдер мин,
Башка манзарадыр җаныңда.
Ә мин исә, беркемне дә түгел,
Сине генә күрәм янымда.

Төш нәрсә ул! Күрәсең дә — бетә.
Бик күбесе шундук онтыла.
Ләкин кеше тик бер күрә алган,
Онтылмаслык төсле төш була.

Мин дә, шул бердәнбер төш шикелле,
Йокың бүлеп кералсам иде...
Төштә генә түгел, өнеңдә дә
Төсле төшең булалсам иде!

* * *

Моңа кадәр әллә чын сөюнең
Ни икәнен белми торгангамы,
Сизми калдым синең күзләреңнең
Төпкеленә кереп югалганны.

«Бәхетлеләр андый булмый!» — диеп,
Йөрәккәем әллә алдашканмы?
Сизеп тордым татылмаган хисләр
Өеренә кереп адашканны.

Белдем инде синең һәр сулышың
Үземнеке булып тоелганны.
Тәнем генә түгел, җаным белән
Йөрәгеңә килеп сыенганны.

Белмим әле: гамәл китабында
Бәхет шәҗәрәбез ничегрәк.
Тик барыбер тапмый тилмерүдән
Табып югалтулар җиңелрәк.

## *Минем өчен бары шул җиткән...*

Уйсу гына җиргә күлләр күчкән,
Ай шәүләсе суларын кискән...
Синнән башка күңел көткәнем юк,—
Минем өчен бары шул җиткән.

Ай сарысы микән, сагыш микән
Күл өстенә сары төс сипкән...
Белеп яшим синең бар икәнне,—
Минем өчен бары шул җиткән.

Сары гына төшкән күл суларын
Ярларына ятып кем эчкән?..
Уйлыйм, ул да мине көтәдер, дип,—
Минем өчен бары шул җиткән.

Күл суларын эчеп үлән үскән,
Үлән өсләренә чык төшкән...
Көтә белү олы бәхеттер ул,—
Минем өчен бары шул җиткән...

* * *

Эшең күп шул —
Тын алырга
Вакытың тардыр кебек.
Ә мин сагыш тәлгәшемне
Китердем сиңа өзеп.
Китердем дә —
Көтеп торам
Миңа күз салганыңны,
Тәлгәшемнең бер бөртеген
Үрелеп алганыңны...

## *Үкенмә*

Кешеләргә язган бәхет безгә язмаган,
Язмыш безне мәхрүм иткән сөю-назлардан.
Юлларыбыз төрле якка адашып киткән,
Аерым-аеры, гел заяга гомерләр үткән.

Көтмәгәндә таптым сине гомер көземдә,
Эзләгән булгансың икән мине үзең дә...
Сагыш тулы күзләреңә барып сыендым,
Сөю-сәгадәт диңгезенә чумып коендым.

Зая узган гомерләрне уйлап үкенмә,
Шатланыйк без бер-беребезне тапкан өченгә.
Күзләреңнән бары бәхет яшьләре тамсын,
Безнең сөю төсе булып шушы җыр калсын.

* * *

Үткән сөю, узган хәлләреңне
Бәйнә-бәйнә сөйләп интекмә.
Мин үзем дә ышаначак түгел,
Синең хакта сүзләр ишетсәм.
Мин бүгеннән сине кабул иттем,
Тормышыңны беләм бүгеннән.
Үткәннәрең өчен көнләшүләр,
Уй йотулар белән тилмермәм.
Минем өчен әле синең тормыш
Бүгенгедән генә башлана.
Үткәннәрең миңа кирәк түгел,—
Гафу үтенүдән башлама.

* * *

Иренемдә — иренеңнең тәме.
Татлы назы әле китмәгән...
Иртәләрен иртә булыр, дипме,
Безнең сөю, никтер, кичләгән.

Кичләгән дә, никтер, кичеккән шул —
Өзелдең ни, өзелмәдең ни...
Күзләрдә дә сөю эсти күңел —
Сүрелдең ни, сүрелмәдең ни...

Нәрсә соң бу?! Язмыш каргавымы?
Әллә Ходай биргән бүләкме?
Гомеремнең янар язларында
Нигә сөю бик әз эләкте?

Кабаланам. Куркам. Өзгәләнәм.
Килә әле сөеп каласым.
Гомеремнең әле көзе генә.
Ак карлы кыш килер аннан соң...

* * *

— Мин сиңа нәрсәгә? — дисең син,—
Безнең бит тормышлар аерым.
Син шатлык дәрьясын гизәсең,
Мин иңлим диңгезен кайгының.
— Мин сиңа нәрсәгә? — дисең син.—
Барыбер без бергә булмабыз.
Беребез дөньяга иртәрәк,
Беребез соңарып туганбыз.
— Мин сиңа нәрсәгә? — дисең син.—
Буталган, чуалган язмышлар.
Кемнәрдер сәбәпсез рәнҗегән,
Бихисап җыелган каргышлар.
— Мин сиңа нәрсәгә? — дисең син.—
Күрешәбез барыбер бик сирәк...

Мин белмим: минсез син ничектер.
Ә миңа... Син кирәк! Син кирәк!
Син барга мәгънәсез, максатсыз,
Җимерек тормышым көйләнде.
Син барга кайгыны шатлык дип,
Алданып яшәргә өйрәндем.
Син барга сүрелгән күңелем,
Терелеп, мәңгелек ут алды.
Синең бу дөньяда барлыгың
Мине юк булудан коткарды.
Мин — сиңа, син миңа нәрсәгә
Кирәген тик вакыт хәл итәр...
Яратсаң җан атып, өзелеп,
Шул җитәр. Шул җитәр. Шул җитәр!

* * *

Битәрләмә, җаныем, үз-үзеңне,
Нигә күрдем, диеп, ник сөйдем?!
Бәлкем, табуыдыр йөрәгеңнең,
Ниһаять, көн килеп, үз тиңен.

Икеләнмә, «алай» итсәм, диеп,
«Болай»лары китәр кайларга?
Ходай язган булса, барысы да
Барып җитәр беркөн «җай»ларга.

Тиргәмә дә бу фани дөньяны,
Көткәнчә түгел, дип, азагы.
Күпме генә «тәртәгә типсәк» тә,
Без күрәбез Ходай язганны.

Курыкма син, сыен иңнәремә,—
Җаның терәр урын бар анда.
Гали шан җәнабе* җәннәт өчен
Шөкер итик, әйдә, Аллага!

* Бөек, мәртәбәле.

* * *

Авызларыңа каратып
Торасың, сүз сөйләсәң.
Җаннарыма ял буладыр
«Азамат»ны, «Төнбоек»ны
Йә «Уел»ны көйләсәң.
Дога булып ишетелә
Сөйләгән һәрбер сүзең.
Телең белән бергә сөйли
Иренең, кашың, күзең.
«Ярар...» — диеп әйтеп куйсаң,
Ярамаса да, ярый.
«Уф, Алла...»ны синең кебек
Беркем дә әйтә алмый.
«Бетәбез икән...— дисең син,—
Өлгерми җитәргә дә...»
Синең белән булганда мин
Ризамын бетәргә дә.

* * *

Синең белән бергә яшәү
Дөрес түгелдер сыман:
Көненә мең аерылам,
Көненә мең кушылам.
Көненә мең киңәш сорыйм
Кеп-кечкенә йөрәктән.
Гел шикләнеп кенә торам
Минем сиңа кирәккә.
Дөрес түгел кебек синең
Сөйләгән бер сүзең дә...
Мөлдер-мөлдер миңа юри
Карый кебек күзең дә...
Гел каранып кына торам,

Алып китәр, дип, ятлар...
Кая китте, дип, сагынам
Шиксез яшәгән чаклар...
Тагын мең төрле шигемне
Куа-куа таратам...
Тик бер нәрсәдә шигем юк —
Өзелеп-өзелеп яратам!

* * *

Менә инде бер көн синсез яшим...
Мәңгелеккә түгел түгелен...
Алыштырып булмый берни белән! —
Синсез яши алмый күңелем!

Менә инде бер көн синсез яшим...
Тулган айсыз яшим... Кояшсыз...
Шатлыкларсыз яшим. Көлүләрсез.
Сөеп туймас сихри дөньясыз!

Менә инде бер көн синсез яшим...
Белмим иртәләрем, кичемне...
Бер көн түгел, хәтта бер минут та
Күрми яши алмыйм мин сине!!!
...Бүген кабат шуны төшендем.

* * *

Язгы аяз күктә төсмерләнә
Тулган айның гына шәүләсе.
Өзелепләр лә карыйм олы юлга —
Күренмәсме җаныем гәүдәсе.

Төннәрендә, җаныем, адашмассың,
Тулган айга карап юл чыксаң.
Менәргә дә әзер айга кадәр —
«Әйдә» диеп, миңа кул сузсаң.

* * *

Көнемнең ничә сәгате
Үтте лә сине көтеп.
Кояш батуларын көтеп,
Ай торды сабыр итеп.

Ә мин сабыр итәлмәдем,
Әрле дә бирле килдем.
Көтүнең нәрсә икәнен
Сине көткәндә белдем.

Гөлләремне бер тәрәздән
Икенчегә күчердем,
Тәрәзәдән карый-карый,
Көтү чире кичердем.

«Харап икән! Көткән...» — диеп,
Миннән көлгән кешегә
Мин сине көткән шикелле
Көтү чире бирсен лә...

* * *

Белгән кебек кайдан килдең
Минем сагынганымны.
Күзләрең ник читкә бордың,
Әллә сагынмадыңмы?

Әллә миннән аерым чакта
Башка ярлар сөйдеңме?
Шуны әйтеп кире китәр
Өчен генә килдеңме?!

Әйтмә, җаным, әйтмә, җаным,
Күңелем сүрелмәсен.
Мәңге ялганмаслык булып
Үзәгем өзелмәсен.

* * *

Шулайдыр... Бик сәер тоеладыр
Сыенасым килүе иңеңә.
Нишлисең... Гомерем буена
Язмыштан наз сорап тилмерәм.

Шулайдыр... Бик көлке тоеладыр
Янарга теләвем «яшьләрчә».
Нишлисең... Кабыналмый алынды,
Дөньяда ни гомер яшәп тә.

Шулайдыр... Бик гаеп тоеладыр
Кешечә яшәргә теләвем.
...Рәхмәт! Айнытып җибәрде
Чакырып та яныма килмәвең...

* * *

Мин аңлыйм,
мин сизәм —
син миннән качасың,
Күзләре җиктән, дип, сөюем бакчасын.
Күрәмсең:
күзләрнең
ямьнәре ямьлерәк,
Күзләрнең алмасы татлырак, тәмлерәк.
Карасаң,
аңларсың
күзләрем моңыннан:
Моң түгел, күңелнең назлары тум-тулган.
Кулыңны селтәмә,
күзләре җиткән, дип.
Язлары, җәйләре сөюсез үткән бит!
Күңелнең аклыгы
чәчләргә сарылган,
Күз җиткән. Сөюнең җетесе кабынган.
Әзермен
сөяргә
әрнетеп,
яндырып:
Китмә син күземне берьялгыз калдырып.

* * *

Ашыктырма. Көн-сәгатьләр кума,
Үзгәртергә теләп халәтеңне.
Тормыш үзе җайлар барысын да,
Үзе барлар булдык-сәләтеңне.

Ашыктырма. Күңелеңнән мине
Куып кына хәлең үзгәрерме?
Узган сөюләрдән канап калган
Күңел яраларың төзәлерме?

Ашыктырма. Минем дә бит сиңа
Сөю хисем әле анык түгел.
«Бусы чындыр» диеп алданудан
Сулган йөрәк, гаҗизләнгән күңел.

* * *

Мәңге тынмас сагышым син,
Мәңге төзәлмәс ярам,
Уйлап туймас татлы уем,
Көнне төн иткән карам.

Еллар мине синнән куа,
Мин һаман сиңа барам.—
Төгәлләнмәс озын юлым,
Мәңге җитәлмәс арам...

* * *

«Яратма син,— дисең,— мине алай,
Мин бит лаек түгел сөюгә...»
Лаекларны гына сөяр өчен
Яратылган җаным түгел лә!
Яратсам мин, бары шулай гына —
Бар җанымны биреп яратам.
Бик сәердер, беләм, яратмаган
Күзләр белән миңа карасаң.
Бик сәердер... Сәер генә түгел,
Юләрләнгән, тиле кебектер...
Акыл белән яшәү өчен, бәлкем,
Кеше яратмаулар тиештер.
Яратырга тик үзеңне генә!
Башкалардан яраттырырга!
«Яратам!» — дип җан атучыларга
Сәерсенеп карап торырга.
...Юк шул, җаным! Нигәдер без андый
Туфраклардан яратылмаган.
Яры өчен утка, суга төшкән,
Алдын-артын карап тормаган.
Яраткан без бары җан канатып,
Күз яшьләре түгеп, аһ орып;
Кер тидерми җанына, тәненә,—
Ап-ак дигәннәрдән ак булып.
...Яратудан мәхрүм туганнарга
Бары салкын акыл баш булыр.
Күрсәтмәсен Ходай! Андыйларның
Йөрәк урынында таш булыр.

* * *

Борчуларың, әйдә, үземә бир,
Мин аларны җиңел күтәрермен.
Борчу түгел, авыр кайгыларны,
Ачы хәсрәтләрне үткәрдем мин.

Уйчан күзләреңә яшь бөялгән...
Тукта, синең өчен үзем елыйм.
Күңел гөлләреңнең сулган чагы,—
Үзем ундырышлы туфрак булыйм.

«Мине сөймиләр...» — дип газапланма,
Үзем яратырмын сине «үлеп».
«Сөю» дигән гаҗәп авыр йөкне
Күтәрик без икәү тигез бүлеп.

* * *

Күзләреңне үбеп, иренемә
Назлы карашыңны сеңдерәм.
Синекедәй моң-сагышлы күзләр
Беркемдә дә юктыр, бергенәм.
«Юләр лә бу...» — диеп көлмә генә,
Яратмавың булса, сиздермә.
Язмышымнан сине дәгъва итмим,
Хыялыма кил син бер генә.
Кеше сүзләренә колак салма,
Карамачы миңа чит итеп.
Яратасым килә гомерлеккә
Хыялыма китеп, нык итеп.

* * *

Сагынуларга түзми, күзләреңнән
Сагыш тамчылары түгелсә,
Төннәрендә, салкын мендәр кочып,
Ялгызлыктан җаның өзелсә,
Исеңә төшер синнән мең мәртәбә
Ялгызрак тагын бераү барын...
«Ялгызлардан ялгыз кем?» — дисеңме?—
Мин инде ул, мин инде ул, җаным...

* * *

Мине сагынудан синең дә
Үзәгең өзеләдер,—
Бу дөньяның аклыклары
Дөм кара күренәдер.

Ничек исә юатыйм, дип,
Үзәк өзелүләреңне
Берәм-берәм саныйсыңдыр
Минсез мизгелләреңне.

Берәмләп өзәсеңдер,
Җаныңа тезәсеңдер...
Мин булсам түзалмас идем,
Син ничек түзәсеңдер...

* * *

И, җанашым, җаным ла,
Әйтәм тагын-тагын да:
Күрмәгәнгә үзеңне,
Сары алды йөземне.

Бердәнберем, бер генәм,
Синең өчен тилмерәм.
Көннәр буе уемда —
Үзең юк шул куенымда.

И, аппагым, ак кынам,
Тик син диеп аһ орам.
Бармы хәбәр салырың?—
Бетеп бара сабырым.

* * *

Бар исемнәр арасында
Исемең тансык булыр.
Көннең кайсында килсәң дә,
Ишегем ачык булыр.

Сине көткәндә һәрвакыт
Күзләрем дүртәү булыр.
Башкаем ялгыз булса да,
Мендәрем икәү булыр...

* * *

Теләмәсәң сөюләрдән
Саргаеп үлгәнемне,
Гел «Яратам!» дип әйтергә
Өйрәт иреннәреңне.

Үлеп китмәсен бу, дисәң,
Төелеп яшьләренә,
Җылың белән, назың белән
Өмет бир яшәремә.

Караган саен сөю ал
Мөлдерәмә күземнән,
Дорфа сүзләр әйтеп саксыз,
Биздермәче үзеңнән.

Эчеп туйма ширбәтләрен
Мәхәббәт чишмәсенең.
Кадерен белсәң генә, сөю
Яшерми чишәр серен.

Яныйк, әйдә, икәү бергә
Мәхәббәт учагында.
Яшәү кадере икеләтә
Тоелыр шул чагында!

# *Димәс идем*

— Матур булсын,— димәс идем,
Акыллыга тап булсам,
Тышым каралып бетсә дә,
Җаным белән ак булсам,
Карамас идем кешенең
«Пычрак» дигәненә,
Бәхетле булалсам әгәр,
Юлыгып сөйгәнемә,
Калган гомеремдә, бәлки,
Рәхәт күрер идем,
Яхшылыкның колы булып,
Тезләнеп йөрер идем.
— Алтын кирәк,— димәс идем,
Көмешкә туяр булсам,
Ике башны бер ләхеткә
Янәшә куяр булсам,
Җанымны синеке белән
Бергә өзеп алсалар,
Ризамын, тәмуг утына —
Синең белән салсалар...

* * *

Саубуллашмый гына китеп бардың.
Күзләр яфрак сипте эзеңә...
Яңгырлары кунды күзләремә,
Көзнең сары төсе — йөземә.

Сызып ташлап мине күңелеңнән,
Яшисеңдер рәхәт тынлыкта...
Җан тынычлыгымны урладың да,
Салып киттең мине моңлыкка.

Җиңел генә китә алмас идең,
Сөйгән булсаң мине син шашып.
Кире кайтыр юллар ябылган шул,
Киткәннәргә генә... гел ачык...

* * *

Килми инде сине сагынасым,
Килми гел-гел сине сөйлисем.
Килер чакта килә белмисең лә,
Китәр чакта китә белмисең.

Хәйран калып сиңа карап торам:
Бер җирең юк табыныр, сөярлек...
Бар дөньямны онытып сине сөю —
Юләрлектер минем, юләрлек...

Җае килгән саен менә шулай
Үз-үземне, сине орышам.
Җүләрләнә язып сөйгән җанны
Синнән биздерергә тырышам.

Дусларым да мине орышалар:
Ташла, диеп, исән чагында...
Әйтү генә ансат! Сөйгән саен
Сөям сине тагын, тагын да!..

...Килер чакта килә белмисең лә,
Китәр чакта китә белмисең.
Килә гел-гел сине сагынасым,
Килә гел-гел сине сөйлисем!
И... ярым!

* * *

«Ташлама»,— дисәм дә, бәгърем,
Мине ташларсың инде.
Назлы куеныңда җылына
Хәзер ятлар шул инде.

«Өзмә үзәкне!» — дисәм дә,
Барыбер өзәрсең инде.
Мин түземсез, ә син түзем,—
Мәңге түзәрсең инде.

Мин сабырсыз... Ә син, бәгърем,
Бигрәк сабырсың инде!
Шул сабырлыкларың белән
Ятка калырсың инде.

* * *

«Оныттым» диеп уйлама,
Үзеңнән узалмассың.—
Исемем сызып атарсың,
Җисемем сызалмассың.

«Киттем» дип уйлама миннән,
Син алай италмассың.—
Үзеңнән китсәң китәрсең,
Ә миннән киталмассың.

Мин бит җаным белән сөям,
Акылым белән түгел.
Мине, бер яраттың икән,
Оныту мөмкин түгел.

* * *

Бәхеттән әйләнсә башларың,
Шатлыктан буталса хисләрең,
Сагышлы моң булып, төннәрдә
Мин синең исеңә төшәрмен.

Сагыштан саргайса йөзләрең,
Мин кабат исеңә төшәрмен,
Иң кирәк, шифалы сүз булып,
Наз булып җаныңа күчәрмен.

Ахыргы сулышың алганда
Соң кабат исеңә төшәрмен —
Гомерем учагын сүндереп,
Мин синең яныңа күчәрмен.

* * *

Юатмачы, язлар килер, диеп,
Карлар эреп бетәр, диеп, тиздән.
Синең — миңа, минем сиңа юлым
Карлар күмгән инде. Мәңге күмгән.

Юатмачы, яңарыр, дип, хисләр,
Үтеп китү белән кышкы салкын.
Дөрләп янар күңел учагымда
Сүнеп бара инде соңгы ялкын.

Юатмачы, минем дә, дип, шулай
Үз-үземне аңлый алмас чагым.
Сине сөйгән кебек беркемне дә
Сөеп булмас инде шулай тагын.

Нишләдем соң әле? Нишләдем мин?
Нигә шулай кинәт үзгәрдем?
Җуелып калды еллар чоңгылында
«Мәңге сөям!» — дигән сүзләрем.

# *Китә алсаң, үзең кит миннән*

Яратканым өчен сине өзелеп
Беркайчан да кире үкенмәм.
Яратмасаң, син яратма мине,
Китә алсаң, үзең кит миннән.

Сине нигә шулай яратканым
Күпме яратсам да төшенмәм.
Таба алсаң, син тап җавапларын,
Китә алсаң, үзең кит миннән.

Синең барлыгыңа сөенә-сөенә,
Күпме гомер юлы үтелгән.
Яши алсаң, минсез яшәп кара,
Китә алсаң, үзең кит миннән.

Йөрәк соңгы тибешен типкәндә дә,
«Калма миннән!» — диеп үтенмәм.
Кала алсаң, үзең калып кара,
Китә алсаң, үзең кит миннән.

Мине шулай яратмавың өчен
Син булырсың беркөн үкенгән.
Соңга калып миңа башың иеп,
«Китмә миннән!» — диеп үтенгән...

* * *

Әзме-күпме тәҗрибәм бар хәзер —
Арыналам кирәкмәс уйлардан,
Арыналам кайгы-сагышлардан,
Җансызларга кырын карый алам.
Куып җибәралам дошманымны,
Таный беләм йөрәк дусларымны,
Каршы барам ярсып искән җилгә...
Тик нигәдер арыналмыйм синнән.
Куып карыйм сине, тиргәп карыйм.
Әллә нинди ямьсез сүзләр әйтеп.
Күз ачып йомарга өлгергәнче,
Син туласың күңелемә кайтып.
Бар җанымны биләп аласың да,
Уйлатасың бары үз хакында...
Уйлыйм сине бәхет-шатлык чакта,
Уйлыйм сагыш, хәсрәт, кайгы чакта...
Гомер буе синнән арыналмам!
Табылмастыр сәбәп-сылтавы да...
Арыналмас кайгым бугай шул син,
Арыналмас йөрәк сыктавым ла...

* * *

...Уз, тәртипкә китер дөньямны.
*Роберт Әхмәтҗанов*

Ничек түзәсең син сагынмыйча,
Мин бит сине шундый сагындым.
Уйлыйм, уйлыйм, уйлыйм һаман сине,
Белмим уйламаган чагымны.

Ничек түзәсең син мине күрми,
Мин йөз барып кайтам яныңа.
Тәрәздәге гөлләр. Сөлге. Сабын...
Хәтта Бим* да сине сагына.

Синнән калган киемнәрне исним.
Синең исең килә. Сулышың.
Чәй эчкәнең сагынам. Көлүеңне.
Болай гына басып торышың...

Ялган горурлыкка бирелеп шулай
Өзгәләрсең тагын, тагынмы?!
Кил йөгереп тизрәк минем янга,
Уз. Тәртипкә китер җанымны.
Мин бит сине үлеп сагындым...

...Ничек түзәсең син мине күрми?!

* Бим (бик иркә малай) — этебез.

* * *

Син инде «үлгән» идең...
Мин сине «күмгән» идем...
Онытырмын. Кабат искә
Төшермәм, дигән идем.

Аклы күлмәгемне салып,
Караны теккән идем...
Исемеңнең һәр хәрефен
Җилләргә сипкән идем...

Исемеңнән, җисемеңнән
Тәмам бизенгән идем...
Юньлелеккә түгелдер бу,
Диеп сизенгән идем.

...Хәрефләп җыеп, исемең
Җилләр кире китерде,—
Сине өзелеп яратуым
Кабат искә төшерде.

Дөрли-дөрли дөрлимен дә
«Гөлт»ләп кинәт кабынам...
Яратам сине! Яратам!
Сагынам! Үлеп сагынам!

Казып алам җисемеңне
Күңелем зиратыннан...
Сөеп була, үлеп булмый
Икән «үлгән» артыннан.

Күз күрә. Колак ишетә.
Тел бар исемең дәшәргә.
Шулай булгач, үлмик әле!
Әйдә, кабат яшәргә!

* * *

Чәчләрем озын чагында
Кадерен белмәгәнмен,
Толымнарым парлы итеп,
Икедән үрмәгәнмен.
Кадерләре беленмәгән
Тормыш парлы чагында.
Үзәкләрем өзелеп китә
Парлыларга карыйм да,
Ялгызларга карыйм да...
Кыскарды хәзер чәчләрем,
Пар-парлап үралмамын.
Җанымны бирәм, дисәм дә,
Мин сине куралмамын.
Куралмамын чәчләремнән
Сукмаклар үрдерсәм дә...
Сагынуымнан басма салып,
Кай якка йөгерсәм дә...
Уңнарга йөгерсәм дә,
Сулларга йөгерсәм дә...

## *Кем белә?..*

Көлүең тора гел исемдә...
Яраттым күзләрең өчен дә...
Чәчләрең өчен дә яраттым... —
Синме соң әллә яр-канатым?!

Синме соң гомерем буена
Килер дип төшләрдә күрелгән?
Ә бәлки алай да түгелдер... —
Чын дөрес җавабын кем белгән?

Гел аек яшәлгән бер мәлдә
Рәхәт бит хисләрдән исерү...
Ни белән бетәрен белмичә,
Сагышлы газаплар кичерү.

Кем белә: бәлкем, бу хәлләрнең
Азагы бөтенләй булмас та...
Ярату кирәк ул кешегә —
Картлыкны тоймаска... Сулмаска...

* * *

Каршы чыктым юлларыңа —
Килмәдең көткән чакта,
Йөрәгемдә синә гына
Мәхәббәт йөрткән чакта.

Юлларымны карлар күмде,
Сүнде өмет учагы.
Бетмәс сагыш булып калды
Гомеремнең шул чагы.

«Яңа юллар салыйк,— дисең,—
Яңартыйк йөрәк утын...»
Кар астында калган юллар
Кадерлерәк шул, дустым!

# *Килә күрмә түгел...*

Исләреңә төшсәм, килә күрмә,
Башлыйк, диеп, барысын яңадан.
Сине кабат алай сөя алмам,
Кабына да алмам, яналмам.

Үзәгеңне өзелдермә инде
Назларымны исеңә төшереп;
Килә күрмә, зинһар, күрә күрмә,—
Йә куярмын сине кичереп.

Мин оныттым сине. Сөймим инде.
Бары искә генә аламын...
...Килә күрмә түгел! Китә күрмә!—
Синсез мәңге яши алмамын!

* * *

Сулышыңның һәр чемкелен тоям,
Хәнҗәр карашыңны — үткәндә.
Минем сиңа әйтер бер сүзем юк,
Рәнҗешләрем, каргыш, үпкәм дә...

Күңелемдә сиңа җылы беткән,
Кулларымның сулган назлары...
«Ул бар иде тормышымда...» — дигән
Бер хатирә бары — калганы.

Их! Бар иде... Бар иде бит сөю...
Йокысыз төн... Шигырь... Күз яше...
Янып сүнү, бәлкем, бәхеттер дә,
Кабыналмый пыскып үлгәнче.

* * *

Әгәр минем хакта сорасалар,
Син башыңны түбән иярсең.
«Ярар инде, орышмагыз мине,
Ялгышлык булды ул...» диярсең.

Әгәр синең хакта сорасалар,
Мин башымны түбән имәмен.—
Орышу түгел, җаным алсалар да,
«Язмышым ул минем» диярмен...

* * *

Чыгыйк та без япан кырларга,
Тергезик икәүләп бер учак.—
Кайгырма, ягарбыз кайгыны —
Миндә бит шатлыклар бер бөртек,
Кайгылар бер кочак... мең кочак...

Китик тә исемсез илләргә,
Тергезик икәүләп бер шәһәр.
Миндә бит бер бөртек шатлык бар —
Нигезгә салырга шул җитәр...

Меник тә иң биек тауларга,
— Кил! — диеп дәшик без бәхеткә...
Тормышта аерым булсак та,
Салырбыз башны бер ләхеткә...

Аһ!
Ник икән адәми затларга
Акыллар керә би-и-и-ик соңарып?! —
Юк шул ул безгә тиң юлдашлар —
Исемсез юлларга чыгарлык!..

* * *

Мин сине сөйгән идем,
Янган да көйгән идем.
Сиңа гына бар җанымны,
Тәнемне биргән идем.

...Бары да бетте инде,
Сөюләр үтте инде.
...Мин сөйгәнгә киттем,
Ә син...
Яратмый киттең инде.

Сизә күңел: син барыбер
Яныма киләчәксең,
«Кабатлыйкчы шул көннәрне,
Аерылмыйк»,— диячәксең.
Сөйли башлавымны белгәч,
Егылып «үләчәксең».
Ялгызың үләчәксең.

* * *

Син упкынның кырыенда инде:
Ярты адым калган очарыңа.
Тик шулай да сыенасың килми
Минем сөю тулы кочагыма.
«Сабыр итче,— дисең,— сабыр итче,
Әйдә, тагын бераз гына көтик...»
Без болай да инде көтә-көтә
Көтүче хәленә калып беттек.
Нәрсә әйтим?! Рәхмәт инде сиңа —
Сөю кадерен белмәгәнең өчен.
Чакырылмаган кунак булып килдем,
Шул ук тамга белән кире китим.

Нишлисең бит, ышанасың килми
Язмыш үзе биргән бу шатлыкка.
...Сау бул инде. Соңгы сүзем сиңа:
«Ялгызлык иленә — мең фатиха!»

* * *

Миңа күптәннән аңларга вакыт:
Син һаман миннән көлеп йөрисең.
«Миңа нишләргә?!» — диеп сорасам,
«Көталган кадәр көт әле...» — дисең.

Күңел өченгә ярты елга бер
Чәчәк тә тотып килә белмисең.
Кеше шикелле өзелеп елый
Йә рәхәтләнеп көлә белмисең...

Җавабы гади. Үзеңнән башка
Беркемне дә син сөя белмисең.
Мин сине шулай бөекләткәч тә...
Чынлыкта бит син беркем түгелсең.

Илле яшеңнән узып китсәң дә,
Син бала кебек юләрсең әле.
...Минем барлыкка күнгән шикелле,
Мин юклыкка да күнәрсең әле...

* * *

Хәтәр сүздән, хәнҗәр сүздән
Хәйран булдым, калдым өнсез...
Өзелеп сөйгән ярым булса,
Әйтер идеме авыр сүз?!

Борылды да китте үзе,
Әйтерсең берни булмады...
Гамьсез бер сүз йөрәгемнең
Кыл яртысын уеп алды.

Яман бер сүз, хәтәр бер сүз
Таштай итте, күңел, сине!
Өзелеп сөйгән ярым булса,
Әйтмәс иде андый сүзне...

* * *

Бүген көчле яңгыр булыр, ахры,—
Төшләремдә никтер еладым.
Явар төсле яңгыр. Белсәм дә мин
Кышлар җиткәч алай булмавын.

Миңа бар да соңга калып килә.
Шулай булгач, нигә яумасын?
Кышларда да яз китерер хәлем
Син аңларсың әле, аңларсың.

Аңларсың ла, бәгърем, соңга калып,
Төшләреңдә син дә еларсың.
Минем кебек, юкка өметләнеп,
Яңгыр явары юрарсың...

* * *

Рәнҗеп калма...
Авыр булыр миңа...
Зинһар, рәнҗи күрмә,—
Иртәгә мин китәм.
Телисеңме,
Әгәр «әйе» дисәң,
Хәсрәт-моңнарымның
Әсиреннән сине азат итәм.
Телисеңме,
Онытып үз-үземне,
Вакытларның бутап санын-чутын,
Иртәгә үк синең күңелеңнән
Чыгып китәм, дустым.
Шикләнәсең икән
Әгәр минем
Моңнарымның сине көткәненә,
Синең күңелеңнән
Иртәгә үк
Ялгыз башым чыгып китәм менә...
Гафу үтенмәмен
Ак чәчеңнең
Тәлгәшенә иренемне куеп...
Уфтанырмын ләкин күңелемнең
Фәкыйрь калганлыгын кабат тоеп.
...О-о-зы-ы-н булды сиңа килер юлым.
Вакыты да узган булган икән...
Назларымнан, сөю газабыннан
Азат итәм сине, азат итәм...

* * *

...Төшләремдә күрү беләнмени?! —
Күзем ачкач, өнемә кучмисең.
Дөнья тулы кеше арасында
Җан сыендырырга син җитмисең.

Кеше барсына да күнә, диләр,
Ялгызлыкка ләкин күнекмисең.
Күңел күзләремнең түрендәсең,
Күрер күзләремә син җитмисең.

«Килче!» — диеп, сиңа сөрән сала
Җан авазым! Нигә ишетмисең?!
«Сүндыр инде...» — диеп икеләнмә,—
Кайчан килсәң дә син кичекмисең!

* * *

Төн сәгате күптән суккан инде,
Шәһәр чумган тирән йокыга.
...Әле яңа йоклап киткән идем,
Уятты йокымнан эт елап.

Нәрсә сорый икән ул Ходайдан,
Бер сөякме, җылы өн микән?
Аны менә шулай, кызганмыйча,
Урамга ташлады кем икән?

Мине дә ташлады сөйгән ярым,
Минем кебек сөя алмады...
Әллә ярый, мин бит шул ташландык
Эт хәлендә торып калмадым.

...Мин дә елыйм төнге эткә кушылып,
Керфекләрем яшькә чыланган.
Беркемне каргамыйм, рәнҗемим дә...
Бары бәхет сорыйм Ходайдан.

* * *

Безгә нәрсә?! Без күнеккән инде.
Сентябрь дә безгә, май да бер.
Кайда икән без сөясе ярлар?
Их, китәсе иде каядыр...
Их, китәсе иде! Һәм сөясе —
Йөрәк бәгыреңә тигәнче!
«Яратып туялмый үләм инде
Сине генә, сине!!!» — дигәнче.
Юк шул инде! Юк шул.
Без күнеккән...
Эшкә барып, эштән кайтырга.
Эш турында уйлап кич буена,
Төнлә төштә күреп ятарга.
Ә гомерләр үтә! Үтә гомер...
Яңа утыз иде безгә дә.
Өлгерербез кебек иде әле
Чып-чын сөю белән сөяргә.
Узган-киткән. Бары да беткән...
Беткән!
Еллар арасында упкыннар.
Без яши белмәдек.
Улым белән кызым
Миннән акыллырак булсыннар.
Миннән бәхетлерәк булсыннар!
Ә мин нәрсә?
Шигырь белән яшим.
Сердәшем дә алар, ярым да...
Җыр-моң булып мине юаталар
Җанның көе киткән чагында.
Шулай булсын!
Без мескеннәр түгел!
Юкны бар итүче нәселдән!
Дошман түгел, дус та белмәсләрен
Йөрәк сандыгына яшергән...

Без яшәдек. Һәм яшәрбез шулай
Тешне кысып, канын чыгарып...
Бәхет барыбер эзләп табар безне!
Эзләп табар барыбер соңарып.
Ишекне киң ачып килеп керер,
Каршыларбыз назлап һәм сөеп,
«Соңлавын соңладың... Ярар, әйдә,
Соң булса да уң булсын...» — диеп.
Без сөясе ярлар да табылыр,
Бәхет ишекләре ачылгач,
Дөрли-дөрли йөрәк кузы сүнгәч,
Җан дингезе ярсып басылгач...
Килсен генә!
Көч табарбыз әле
Соңгы сулышкача сөяргә,
«Яратып туялмый үләм инде
Сине генә... сине!..» — дияргә...



# IV

*Ә мин нәрсә?!*
*Шигырь белән яшим.*
*Сердәшем дә алар, ярым да...*
*Уыр-моң булып мине юаталар*
*Җанның көе киткән чагында...*

# *Хәерлегә булсын**

«Хәерле...» дип, эш башлаган халкым,
Зур юлларга сәфәр чыкканда,
Кызу урак өсте башланганда,
Мәйданнарда бәйге тотканда.

«Хәерле...» дип, бала битен юган,
«Хәерле...» дип, туйлар уздырган,—
Шуңа күрә йөзе иман нурлы,
Ә эшләре һәрчак уң булган.

Ата-баба гадәте буенча,
«Хәерле...» дип, башлыйк эшләрне,
Хәерле таң, хәерле көн телик,
Хәерле дип көтик кичләрне.

Хәерле кич сезгә, кан-кардәшләр,
Хәерле ел, хәерле гамәл,
Гомерегез хәерлегә булсын,
Илтсен матур көннәргә кадәр!

* Рөстәм Сәрвәров көе.

## *Хәтер җыры**

Сызылып кына таң атканда
Уянам да чумам уйга:
Кая китеп югалдыгыз,
Кай туфракка баш салдыгыз,
Ташлап туган өегезне,
Кай илләрдән табыйк сезне,
Халкымның газиз уллары?

Кош сайраудан ник ярсый күңел,
Сездән хат-хәбәр килер сыман.
Кая китеп югалдыгыз,
Кай туфракка баш салдыгыз,
Кайда сезнең каберегез?
Булмас читтә кадерегез,
Халкымның газиз уллары.

Билгесезлектән җан сызлана,
Җавапсыз кала сораулар.
Көтә сезне сөйгәнегез,
Көтә әти-әниегез —
Әллә шуны белмисезме?!
Торыгыз да сез, илгә кайтыгыз,
Халкымның газиз уллары.

* Рәфикъ Таҗетдинов көе.

# *Торналар кычкырып уздылар**

Торналар кычкырып уздылар.
Кычкырып уздылар өзелеп...
Белмәдем: әллә җыр, әллә яшь идеме...
Тик белдем: өзелде җаннары,
Туган җир каласын сизенеп.

Мин дә шул торналар шикелле,
Юл тотсам җиде-ят җирләргә,
Язмышка ялварам илереп,
Кайтар, дип, тиз көндә илләргә.

Кайтар, дип, калдырма җанымны
Җиде-ят янында тилмертеп.
Илемдә ризамын бәхетем
Булса да бер бөртек, бер бөртек...

Торналар китәр дә, кайтыр да,
Аларның язмышы билгеле.
Язмышка ни язган булса да,
Алмашмам чит җиргә илемне!

* Фоат Әбүбәкеров, Илфат Дәүләтшин көйләр язды.

# *Мәңге яшә, Татарстаным**

Каен урманында умырзая,
Иделләрдә тулып боз китә.
Татарстан, синең һәр фасылың
Минем йөрәгемне җилкетә.

Гүзәллекләр эзләп читтә йөрмим,
Бар илләрдән, илем, гүзәл син.
Аермасын язмыш мине синнән,—
Сагынуларга ничек түзәрсең.

Насыйп булсын яшәү мәңге сөеп
Сине, газиз Татарстаным,
Үз ишләрем монда, үз дусларым,
Үз милләтем — газиз татарым.
Мәңге яшә, Татарстаным!

* Сәйдә Вәлиди көе.

# *Татарстаным минем**

Чәчәкләр, гөлләр иле син,
Татлы җимешләр иле,
Җанга-тәнгә сихәт бирер
Елга-инешләр иле.
Кемнәр генә яратмыйдыр
Үзенең туган җирен.
Кадерледән дә кадерле
Татарстаным минем.

Кешеләрең күркәм синең,
Ягымлы, кунакчыллар.
Егетләрең — иң уңганнар,
Дөнья гүзәле — кызлар.
Кемнәр генә яратмыйдыр
Үзенең туган җирен.
Кадерледән дә кадерле
И газиз халкым минем.

Милли ашлар, кешеләрең
Ил бәһасе торырлык.
Сөеп туймас газиз идем,
Син мәңгелек горурлык.
Иң татлы җимеш кебек син,
Татарстаным минем,—
Бернигә дә алыштырмас,
И гүзәл туган илем.

---

* Илфат Дәүләтшин көе.

# *Без мәңге синеке, Казан!* *

Казан каласы — таш кала,
Барыбызга баш кала.
Безнең яшьлек, безнең язмыш
Шул каладан башлана.

Кушымта:

Казаныбыз — борынгы да,
Казаныбыз — бик яшь тә.
Өлкәннәр аны яшәтә,
Яшьләр һәр көн яшәртә.

Матуррак калалар бар,
Гүзәлрәк илләр бар.—
Ата-баба туфрагыннан
Кадерлерәк ниләр бар.

Кушымта:

Җәйләр җитсә, балкып тора
Гөл-чәчәк урамнарың.
Язың, көзең җанга якын,
Кадерле бураннарың.

Һәр ташында, һәр йортында
Изге тарих саклана.
Без — мәңге синеке, Казан!
Алмашмабыз башкага.

Кушымта:

Казаныбыз — борынгы да,
Казаныбыз — бик яшь тә.
Өлкәннәр аны яшәтә,
Яшьләр һәр көн яшәртә.

---

*«Фәридә-Алсу» дуэты көе.

# Минем кадерлеләрем*

Әткәй-әнкәй, сез булганга
Без туганбыз дөньяга.
Авырлыклар күрмәдек без
Сез янәшә булганга.
Әткәй-әнкәй, ике бөртек
Энҗегә сез тиңнәрем,
Аклык-сафлык өлгеләре,
Минем кадерлеләрем.

Бер-берегезгә терәк булып,
Гомер юлын уздыгыз.
Пар былбыллар көнләшерлек
Матур парлар булдыгыз.
Әткәй-әнкәй, пар канатым,
Мәңге шиңмәс гөлләрем,
Кадерледән кадерле сез,
Газиздән газизләрем.

Өебезнең күрке бит сез,
Ике ярдәм кулыбыз.
Өй түрендә урыныгыз,
Исән генә булыгыз.
Исемегез гел янәшә,
Ай белән кояш кебек.
Бәхетлеләр арасында
Сезгә тиң булмас кебек.

---

* Мөфтәдин Гыйләҗев көе.

# *Изге теләк**

Авылымнан әллә кай якларга
Алып китте мине язмыш җиле.
Ничә кайтсам, капка төбебездә
Әткәм-әнкәм каршы алды мине.

Кабат күрешүләр өмет итеп,
Кайткан юлдан китеп барсам кире,—
Капка төпләрендә, парлап басып,
Әткәм-әнкәм озатып калды мине.

Мең эшемне ташлап, кабат-кабат,
Авылыма кайткан саен мине
Мәңге шулай капка төбебездә
Әткәм-әнкәм каршы алса иде.

* Роберт Андреев, Ганс Сәйфуллин көйләр язды.

# *Сагынам сине, әнием**

Яшел чирәм өсләрендә
Ап-ак томаннар ята.
Иртәнге чыкны уятып,
Әкрен генә таң ата.

Кушымта:

Кошлар уята баласын,
Сайрашырга пар булып.
Әнкәй, бәгърем, сагнам сине
Бер күрергә зар булып.

Күбәләкләр гөлдән гөлгә
Кунаклап оча башлый.
Минем генә йөрәккәем
Өзгәләнә ямь тапмый.

Кушымта.

Үз-үземне юатам мин
Шундый моңсу чакларда,
Илтер, диеп, юллар мине
Син яшәгән якларга.

Кушымта.

* Азат Хөсәенов көе.

# *Әткәем**

*Әткәем Гатуф Гарифулла*
*улына багышлыйм.*

Әткәем, мин сине хәтерлим дә кебек,
Рәсемеңне алып карасам.
Гомергә бер генә күрмәсәм дә сине,
Яратам, өзелеп яратам.

Әнкәем җил-яңгыр тидерми үстерде.
Тормышта ул миңа зур терәк.
«Әнием» дигәндә, «әткәем» дияргә
Син кирәк, әткәем, бик кирәк.

Ишетсәң җырымны, кил минем яныма,
Гомергә калмасаң калмассың.
«Әткәем!» диеп, бер кочаклап үзеңне,
Төзәтим җанымның ярасын,
Җанымның гомерлек ярасын.

Кил әле, әткәем, төзәтим җанымның
Мәңгегә төзәлмәс ярасын...

* Марсель Иванов көе.

# *Туган якка кайтып киләм әле*[*]

Туган якка кайтып киләм әле,
Чишмәләргә ятып су эчәм.
Бала чактан киткән,
Бергә аунап үскән
Җан дусларым белән күрешәм.

Туган якка кайтып киләм әле,
Бурычларым үтәп бетмәгән.
Тәпи басып киткән,
Мине кеше иткән
Туган туфрагымны үпмәгән.

Туган якка кайтып киләм әле,
Газиз әнкәм сагынып көтәдер.
Туган көннән башлап,
Исән-имин саклап
Аның фатихасы йөртәдер.
Әнкәм фатихасы йөртәдер...

* Альберт Шакиров көе.

# Туган-үскән якларым*

Туган-үскән якларым ла,
Болыннарым-кырларым.
Сездә тудым, сездә үстем,
Ләкин сездә тормадым.
Җилләр булып очып килим
Газиз туган ягыма,
Бик сагындым сезне, диеп
Әйтим туганнарыма.

Сусавымны басар кебек
Туган як чишмәләре.
Җилләрнең дә иң назлысы
Шул яктан искәннәре.
Җилләр булып очып килим
Газиз туган ягыма,
Җәйләремә кайтыйм әле,
Кышларыма-язына.

Кадерледән дә кадерле
Туган-үскән ил генә.
Чит-ят җирләр күп булса да,
Туган җирем бер генә.
Җилләр булып очып килим
Газиз туган ягыма,
Бик сагындым сезне, диеп
Әйтим туганнарыма.

* Азат Хөсәенов көе.

# *Мөслимем**

Син минем үз илем, үз әнкәм, үз телем,
Син минем иң татлы җимешем.
Аерылып китсәм дә чит җиргә — еракка,
Көн саен төшемә керерсең.

Кушымта:

Мөслимем, Мөслимем, син бәллүр бишегем.
Җыр булып күңелне тибрәтә исемең.
Кайларда булсам да, яшәсәм, торсам да,
Синнән ваз кичмимен,
Син минем Мөслимем,
Син минем Мөслимем!

Мин синең туфрактан җан алган үз балаң,
Ыгыңа кушылган инешең.
Сагынудан яралган иң матур, иң моңлы
Җыр булып күңелгә керерсең.

Кушымта.

Җанымда юк башка җирләргә урыным,
Онытылыр, сагынмас түгелсең.
Яз саен иленә юл тапкан кошлардай
Әйләнеп кайтырмын — күрерсең.

Кушымта.

---

* Азат Хөсәенов, Сафьян Ибраһимов көйләр язды.

# *Туган көнең белән!* *

Туган көнең синең бүген,
Дөньяга килгән көнең.
«Бу мин!» — диеп, бар җиһанга
Шат хәбәр биргән көнең.

Җыелышкан дус-ишләрең,
Кардәш, туган-тумачаң.
Яшәү кызык булмас иде,
Син дөньяга тумасаң.

Булсын һәрчак җан юатыр
Иң кадерле дусларың.
Йөрәгеңдә дөрләп торсын
Мәңге яшәү учагың.

Котлы булсын, котлы булсын
Син дөньяга туган көн.
Зәңгәр күккә исемеңне
Кояш уеп куйган көн!

Рәхмәт әти-әниеңә
Син булганга бу җирдә!
Иң изге теләкләр телим,
Дускаем, сиңа мин дә!

* Фәрит Хатыйпов көе.

# *Әйдә, биик!* *

Әйдә, биик әле, дисәм,
Ялындырган буласың,
Күзләреңне түбән иеп,
Читтә генә торасың.
Бас әле, бас, бөтен кеше
Кызыгып карап торсын,
Тыпырдатып биюләрең
Күңелгә ярап торсын.

Бөтен кеше биегәндә
Түгәрәккә кермисең,
Әллә юри шаяртасың,
Әллә бии белмисең.
Әйдә әле бер тыпырдап
Биеп алыйк бергәләп,
Син булганда яннарымда
Дөнья миңа түгәрәк.

* Азат Хөсәенов көе.

# *Ач күзеңне — дөнья бу*[*]

Ач күзеңне — дөнья бу!
Синең белән миңа бу!
Рәхәтләрен татый белсәң,
Искитмәле дөнья бу!

Ач күзеңне — дөнья бу!
Күчә кулдан-кулга бу!
Синнән-миннән калыр өчен
Яратылган дөнья бу!

Ач күзеңне — дөнья бу!
Елатып та сынар бу,
Көлдереп тә сынар бу.
Байлыгыңны пыран-заран
Бөлдереп тә сынар бу!
Бөгелдереп, сыгылдырып,
Сындырып та сынар бу!
«Әһ» дигәнче узар бу! —
Газиз әнә шуңар бу!

* Фоат Әбүбәкеров көе.

# *Хуш килдең, Яңа ел!* *

Табын тулы сый-нигъмәтләр,
Дус-ишләр бәйрәм итә.
Яктыра чыршы утлары,
Чыршы утлары.
Саный сәгать минутларны,—
Тиздән Яңа ел җитә.

Кушымта:

Хуш килдең, Яңа ел!
Исәнме, Яңа таң!
Әй, тормыш, мин сине
Яратам, яратам!

Бергәләшеп атлыйк, дуслар,
Һәрбер яңа иртәгә.
Кулларны кулга тотышып,
Кулга тотышып,
Шатлыкларны бергә кушып,
Язсын гомер итәргә.

Кушымта.

Бәйрәмнәрдә якын дуслар
Булсын табын түрендә.
Җыр артыннан җырлар сузып,
Җырларны сузып,
Яшик бертуганнар булып,
Татарстан җирендә.

Кушымта.

---

* Рөстәм Сәрвәров көе.

# *Язлар да җитә инде**

Карлар да бетә инде,
Язлар да җитә инде.
Кар суларына кушылып
Гомер дә үтә инде.

Каршына чыксаң иде,
Кулыңны сузсаң иде.
Барган җиреннән гомерне
Туктатып торсаң иде.

Тукталып торсын иде,
Җәлләгән булсын иде;
Бөтенләй туктамаса да,
Әкренләп узсын иде.

Язгы тамчылар тамганны
Бергә санашсын иде;
Узам дигән чакта гына
Юлын адашсын иде.

...Карлар да бетә инде,
Язлар да җитә инде.
Кар сулары кебек йөгереп
Гомерләр үтә инде...

* Фердинанд Хафизов көе.

# *Яңгыр ява, яңгыр ява**

Яңгыр ява, яңгыр ява,
Бар дөнья сихри монда.
Күңел түрендә сакланган
Такмак яңара шунда:
— Яңгыр, яу, яу, яу, яу,
Тәмле ботка бирермен.
Тәмле ботка — казанда,
Тәти кашык — базарда.
Боткабыз да пешеп чыгар,
Син сибәләп яуганда.

Яңгыр ява, яңгыр ява,
Бөтен күк йөзен каплап.
Нәкъ бала чактагы кебек,
Мин утырам кабатлап:
— Яңгыр, яу, яу, яу, яу,
Тәмле ботка бирермен.
Тәмле ботка — казанда,
Тәти кашык — базарда.
Боткабыз да пешеп чыгар,
Син сибәләп яуганда.

Яңгыр ява, яңгыр ява,
Сафлык тула күңелгә.
Әйдә, сез дә кушылыгыз,
Кабатлыйк бергә-бергә:
— Яңгыр, яу, яу, яу, яу,
Тәмле ботка бирермен.
Тәмле ботка — казанда,
Тәти кашык — базарда.
Боткабыз да пешеп чыгар,
Син сибәләп яуганда.

Бәхет иңсен һәр өйгә,
Шатлык тулсын һәркемгә,
— Яңгыр, яу, яу, яу, яу!!!

---

* Оскар Усманов көе.

# *Кайда сез, ирләр?* *

И, иләр лә, иләр лә,
Аваз салам ирләргә:
Сез, дип, кайсы илләрдә?
Сез, дип, кайсы җирләрдә?
И, һайлар ла, һайлар ла,
Асыл ирләр кайларда?
Бармы безгә сайларга?
И, аһлар ла, аһлар ла,
Җиттек нинди чакларга?!
Кирәк булган сакларга,
Кирәк булган якларга.
И, уһлар ла, уһлар ла,
Җиңеләер һушлар да —
Асыл ирләр юкларга.
И, иләр лә, иләр лә,
Әзермен баш ияргә
Бары асыл ирләргә,
Бары затлы ирләргә!

* Оскар Усманов көе.

# *Исемнәрең дөрес куелган**

Шәмнәр генә кебек төз буеңа
Нечкә итеп билләр уелган.
Фирдәвескәй генә, нечкә билкәй,
Исемнәрең дөрес куелган.

Кара гына шомырт каралары
Күзләреңә синең уелган.
Фирдәвескәй генә, кара күзкәй,
Исемнәрең дөрес куелган.

Гомер юлларында бормалар күп,
Кайсындайкән җуелган?
Фирдәвескәй генә, үзәк өзкәй,
Исемнәрең дөрес куелган.

* Сәйдә Вәлиди көе.

# *Лилия**

Синең буең-сыннарыңнан
Көнләшерлек гөлләр дә,
Кемнәр өчен тугансың да
Үскәнсеңдер кемнәргә.
Ай-ли, Лилиям,
Бердәнберем син, диям,
Бердәнберем генә, димим,
Җан сөйгәнем син, диям.

Исемеңне, гөлгә тиңләп,
Әти-әниең кушкан.
Сөю-сәгадәтләр өчен
Тугансыңдыр тумыштан.
Ай-ли, Лилиям,
Бер янам да бер көям.
Янып, көлгә әйләнсәм дә,
Сүндерегезче, димәм.

Төнбоектай боекма син,
Гөлләрдәй шиңә күрмә.
Насыйп булсаң ярар иде
Бары үзеңә тиңгә.
Ай-ли, Лилиям,
Сөйгән ярым син, диям,
Сөйгән ярым, гына димим,
Язган ярым син, диям!

* Азат Хөсәенов көе.

# *Иделкәем**

Иделемә төшеп, сулар алам,
Иделләрдән чиста сулар юк.
Җан сөйгәнне көтеп яшим һаман,
Күңелемдә башка уйлар юк.

Иделкәйнең биек ярларында
Карлыгачлар гына оясы.
Язмышлардан узмыш булмаса да,
Җан сөйгәнне килми җуясы.

Иделемә карап хәйран калам,
Кайгыданмы — суы болганган.
Язмышлардан узмыш булса булыр:
Мин барыбер сиңа булалмам.

* Фәрит Хатыйпов көе.

## *Байкал күлләренә бардым*[*]

Байкал күлләренә бардым,
Су буйларын буйладым.
Байкал күле «уф-уф» дигәч,
Кайгыдан дип уйладым.

Байкал күлләренә бардым,
Каршы ярын күрмәдем.
«Уф-уф»ларың ишетсәм дә,
Эч серләрең белмәдем.

Байкал күлләренә бардым,
Кабат баралмам инде.
Салкын сулар алып эчтем,
Кабат яналмам инде.

## *Сезнең якка юллар сорыйсы юк*[**]

Сезнең якка юллар сорыйсы юк,
Йөгерәсе дә барып җитәсе.
Сагыну-саргаюның чамасы юк,
Онытылган киче-иртәсе.

Сезнең якка юллар сорыйсы юк,
Йөгерәсе дә барып җитәсе.
Бик сагынса, үзе килер, диеп,
Килми инде, килми көтәсе.

Сезнең якка юллар сорыйсы юк,
Йөгерәсе дә барып җитәсе.
Ике нәүмиз җанны бергә кушып,
Мәңге сөеп гомер итәсе.

---

* Фәрит Хатыйпов көе.
** Алмаз Монасыйпов көе.

# *Сабыр ит син, димәгез...** 

Сабыр ит син, димәгез,
Сабырларым сынды инде,
Сабыр итә-итә-итә,
Сабырсыз булдым инде.

Сабыр ит син, димәгез,
Сабырлыктан ни чара:
Сабыр итмәгән кешегә
Үтмәслек түгел ара...

Килми ярым яныма —
Сабыр итә торгандыр...
Сабыр итмәс, килер, диеп,
Мине көтә торгандыр...

Сабыр ит син, димәгез,
Сабырлар итмим бүтән —
Сабыр канатларым сынды —
Очалмыйм, җәяү китәм...

* Вадим Усманов көе.

# *Язган ярым түгел, калган ярым**

Язган ярым түгел, калган ярым
Яшьлек урманында адашып.
Очраштык та күз яшьләре аша
Бер-беребезгә тордык карашып.

Үткән хатирәләр яңарды да,
Кубарылды сагыш бураны.
Үкенечләр генә булып калды
Гомерләрнең синсез узганы.

Үткәннәрне каһәрләми генә,
Тотыныйк та кулны кулларга,
Калган түгел, язган ярлар булып,
Чыгыйк тормыш дигән юлларга...

# *Нишлим***

Сине өзелеп сөюемне
Ничек аңлатыйм икән?
Йокыларыңнан уятып,
Таң булып атыйм микән?

Әллә шатлык яше булып,
Күзләреңнән тамыйммы?
Сандугач булып сайрыйммы,
Гөлләр булып карыйммы?

Җырлар булып, моңнар булып
Күңелеңә тулыйммы?
Әллә үзем генә булып,
Гел яныңда торыйммы?!

---

* Рөстәм Сәрваров көе.
** Фасил Әхмәт көе.

# *Бураннар**

Сиңа кайтыр юлларымда
Җәяүле буран...
Юлларымны йөгерә-йөгерә
Чистартып куйган.
Колач җәеп каршы алды
Нәкъ синең сыман,
Сиңа кайтыр юлларымда
Җәяүле буран.

Синнән китәр юлларымда
Өермә буран...
Юлларыма өем-өем
Көрт сарып куйган.
Җибәрмәде, кире борды
Нәкъ синең сыман,
Синнән китәр юлларымда
Өермә буран.

Нигә икән юлларымда
Шул ике буран...
Чиратлаша һаман-һаман
Язмышлар сыман...—
Сиңа кайтыр юлларымда
Җәяүле буран...
Синнән китәр юлларымда
Өермә буран...

---

* Рәис Нәгыймов көе.

# Ак күлмәгем*

Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Бер киюдә каралттым.
Яратмавыңны белсәм дә,
Әллә нигә яраттым.
Ак күлмәгем, ак күлмәгем,
Итәге зәңгәр бизәк.
Каерылган кош канатыдай
Әрнеп өзелә үзәк.

Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Алларга манам инде.
Чәчәге сынган гөлләрдәй
Ялгызым калам инде.
Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Алмаштырмам карага.
Дөрли-дөрли янсын әйдә,
Сулар сипмә ярага.

Мин караны кими диеп,
Син дә акны киярсең,
Гомер узгач, күлмәк тузгач,
Бәлки син дә сөярсең.
Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Бер киюдә каралттым.
Яратмавыңны белсәм дә,
Әллә нигә яраттым.

---

* Илфат Дәүләтшин көе.

# Ни өчендер безнең язмыш шундый *

Ни өчендер безнең язмыш шундый,
Караш төрле-төрле, уй үзгә —
Мин язларны кыштан эзләп йөрим,
Соңлап кайтасың син һәр көзгә.

Сиңа язлар соңга калып килә,
Көзләр миңа җитә иртәләп.
Әллә инде язмыш үзе шулай
Юлыбызны куйган киртәләп.

Быел исә син бик ашыккансың,
Ә мин соңлап килдем бирегә.
Очрашканчы инде юлларыбыз
Аймылышкан бугай гомергә.

Аймылышкан бугай табышмаска,
Мәңге эзләп гомер итәргә.
Ни өчендер безнең язмыш шундый —
Көтәргә лә язган... көтәргә...

* Луиза Батыр-Болгари көе.

# *Ярат мине**

Ярат мине матур булганда да,
Ярат мине ямьсез булганда да,
Ярат мине яшел күзләремдә
Шатлык яше тулып торганда да.

Ярат мине усал чагымда да,
Ярат мине назлы чагымда да,
Ярат мине юлда чагында да,
Бер өстәл артында — табында да.

Ярат мине битем юганда да,
Чәчләремне тарап торганда да.
Ярат мине җирдә яз булганда,
Күз ачмаслык көчле буранда да.

Ярат мине гомер сабаннары
Биткә буразналар салсалар да.
Ярат мине чәчкә чаллар кунып,
Тешләр сирәкләнеп калсалар да.
Ярат мине!
Гел хәзерге кебек ярат мине.

* Алмаз Монасыйпов, Вадим Усманов көйләр язды.

# *Көнгә биш кенә минут**

Ялгышлар барын оныт син,
Язмышлар барын оныт:
Кил әле, кил яннарыма
Көнгә биш кенә минут.
Тик биш минут кына кирәк,
Артык кирәкми һич тә.
«Ялгыз итмә»,— дияр өчен
Миңа биш минут җитә.

Каргышлар барын оныт син,
Сагышлар барын оныт.
Күзләремнән күзең алма
Көнгә биш кенә минут.
Тик биш минут кына кирәк,
Артык кирәкми һич тә.
«Мин бәхетле!» — дияр өчен
Миңа биш минут җитә.

Гайбәтләр барын оныт син,
Сәбәпләр барын оныт.
Бәхетем, юанычым бул
Көнгә биш кенә минут.
Тик биш минут кына кирәк,
Артык кирәкми һич тә.
«Мәңгегә кал!» — дияр өчен
Миңа биш минут җитә.

* Альберт Шакиров, Илгиз Баязитов көйләр язды.

# *Сау бул инде**

Сау бул инде... Аерылабыз
Икебез ике якка.
Исләреңә төшерерсең
Җаның өзелгән чакта.

Сау бул инде. Сау бул инде...
«Кал!» — дисәм дә, китәрсең.
Онытмасаң мин көткәнне,
Бәлки, син дә көтәрсең.

Аерылыр минутларның
Сәгате җитеп бара...
Көтәргә җиңел булмасмы —
«Сөймим!» — дип китеп кара...

# *Исеңә төшәр әле***

Күңелеңдә гел яз булмас.
Күзләр дә җитәр әле.
Сөю гөлләрең саргайгач,
Исеңә төшәр әле.

Вакыт җиле чәчләреңә
Кар сибеп китәр әле.
Бу дөньяда мин барлыгы
Исеңә төшәр әле.

Исеңә төшәр, соң булыр.
Эзләрсең, табалмассың.
Яшьлегеңнән мине кире
Кайтарып алалмассың.

---

* Рафаэль Билялов, Илфат Дәүләтшин көйләр язды.
** Рамил Курамшин, Марсель Иванов көйләр язды.

# Әмер*

Берәр хәбәр көтеп яшим
Синең тарафларыңнан.
Каурыйлар алып хат язам
Сабыр канатларымнан.

Җыям да шул хатларымны
Күмәм сагыш күленә,
Күңелемдә ниләр барын
Әйтермен, дип, үзенә.

Ходайга ялварам һаман:
Оныттыр, дип, барлыгын...
Йолкып-йолкып җилгә сибәм
Җанымдагы бар моңым.

...Күрәсең, Ходай әмерендә
Минем язмышым шундый:
Аерыла да алмыйбыз,
Бергә дә булып булмый...

* Ганс Сәйфуллин көе.

# *Мин яратам, ә син юк әле**

Сиңа ярты җаным ярып бирәм,
Бөтенләен бирсәм, үләрмен.
«Юләр лә бу!» — диеп аптырама,
Сине ярatkанга юләрмен.

Телисеңме, күкрәгемне ярып,
Йөрәк тибешемне тыңлатам.
«Дөрес түгелдер...» — дип уйлый күрмә,
«Яратам!» — дип әйтеп туймасам.

Күңелемне өермәләп алган
Сулар сибеп сүнмәс ут әле.
Минем хәлем аңлашылмас сиңа —
Мин яратам, ә син — юк әле...

Беркөн килеп, сүрәнләнгән җаның
Биләп алыр шушы ут инде.
Ул чак миңа аңлашылмас хәлең —
Син сөярсең, ә мин — юк инде...

---

* Роберт Андреев көе.

# *Мин идем ул**

Ай карады диеп белгәнсеңдер,
Тәрәз пәрдәң төшергәнсеңдер,
«Онытты ла мине, килмәде...» — дип,
Төрле уйлар кичергәнсеңдер...
Мин идем ул тәрәзәңнән багып,
Ай нурлары булып уйнаган,
Мин идем ул саран язмышыңнан
Тик бер тамчы шатлык сораган.

Яңгыр елый диеп белгәнсеңдер,
Сөрткәнсеңдер тәрәз өлгеңне...
«Заяларга булды...» — дигәнсеңдер
Мин көтеп үткән гомереңне...
Мин идем ул синең тәрәзәңдә
Көзге яңгыр булып елаган,
Мин идем ул үксез язмышыңнан
Бер күрерлек бәхет сораган.

Тәрәз каршысына килмисеңдер,
Сөртмисеңдер тәрәз өлгеңне...
Гомер буе исләремнән чыкмый
Җанны телгәләгән син инде...
Мин идем ул синең тәрәзәңдә
Бер елаган, кабат нурланган,
Мин идем ул сөюләрем белән
Башкаемны моңга ураган...

* Алмаз Монасыйпов, Ганс Сәйфуллин көйләр язды.

# *Үзең килгәч күрерсең*[*]

Башкаемда синең өчен
Агарган чәчләрем бар,
Күзләремдә синең өчен
Тамасы яшьләрем бар.

Бары синең өчен генә
Тибәсе бар йөрәкнең.
Белсәң иде ничек сыкрап
Өзелгәнен үзәкнең?!

Агын-карасын онытам,
Уйласам синең хакта.
Сөеп-сөелеп туймам кебек,
Ничә гомер торсак та...

Син дә шулай өзгәләнсәң,
Хәлемне белер идең.
Агын-карасын уйламый,
Яныма килер идең.

Әллә ниләр бирер булам,
Сине бер күрер өчен...
Калганнарын әйтеп тормыйм —
Үзең килгәч күрерсең!

---

* Азат Хөсәенов көе.

# Өзелеп сөйгәнгә күрәдер*

Син мине уйлап та карамый,
Көннәрең үтәдер эш белән.
Исеңә төшсәм дә төшәмдер
Йокларга ятканда. Кич белән.

Ә минем... көнен дә, төнен дә,
Иртә дә, кичен дә... син истә.
Үзәгем өзелеп сагынам,
Түзәрлек әмәлем юк һич тә.

Иң изге догадай тәкрарлап,
Мең кабат исемеңне эндәшәм.
Һәрвакыт янында булганга,
Мин синең эшеңнән көнләшәм!

«Көнләмә!» — дисәң дә, мин синең
Эшеңнән көнләшәм нигәдер.
Мөгаен, дөньямны онытып,
Өзелеп сөйгәнгә күрәдер.

* Вадим Усманов көе.

# Ышан миңа*

Иң кайгылы чакларымда
Сыендым барып сиңа.
Беркем аңламаганда да
Аңладың мине. Шуңа:

Кайгылы чакларың булса,
Үземә кил — күтәрмен;
Кайгыларыңның барысын
Үземнеке итәрмен.

Йөз чөермәм — бөтен кеше
Синнән йөз чөерсә дә,
Мәхәббәтеңнән җаныма
Сагышлар бөелсә дә.

Ышан миңа — үз-үзеңә
Ышанмаслык булсаң да.
Яратырмын сине — тоташ
Кайгылардан торсаң да...

* Алмаз Монасыйпов көе.

## *Үпкәләмә**

Таң атканда чык бөртекләрендә
Якты нурлар уйный җем-җем килеп.
Үпкәләмә, иртән йокылардан
Уянганда, күз яшемне күреп.

Көн кызуы арта барган саен
Чык бөртеге кибә яфракларда.
Үпкәләмә, күз яшемә күмеп,
Елый-елый сине йоклатканга.

Ни хәл итим, өметләрне өзми,
Җылы эзлим сүнгән учакларда...
Үпкәләмә, сине үземчәләп —
Күз яшьләрем белән яратканга.

## *Исемеңне саклыйм йөрәгемдә***

Бер генә көн сине күрми торсам,
Сусыз гөлләр кебек янып көям.
Исемеңне саклыйм йөрәгемдә,
Өзелеп яратуның кадерен беләм.

Яратасым килә мәңге-мәңге,
Каршы килми җаным теләгенә.
Башкаемны салам күкрәгеңә,
Сөю-назларымны — йөрәгеңә.

Күңел кошым чут-чут сайрый башлый,
Җанга бәхет иңә, сине күрсәм.
Ятатуның кадерен төшенерсең,
Әгәр минем кебек өзелеп сөйсәң.

---

* Рәис Нәгыймов көе.
** Рафаэль Билялов көе.

## *Син мине күрмәдең**

Син минем иң гүзәл чагымны күрмәдең:
Яшенләп янганын күзләрем.
Син минем иң моңлы чагымны күрмәдең:
Еладым, еладым... түзмәдем.

Син минем иң назлы чагымны күрмәдең:
Аһ орып ятларга сыендым.
Син минем иң иләс чагымны күрмәдең:
Нур булып күкләргә уелдым.

Син минем иң изге чагымны күрмәдең:
Фал ачып, төшемне юраттым.
...Хәзер мин гап-гади Җир заты:
Югалттың син мине... югалттың...

## *Мин күкләргә шундый якын идем***

Мин күкләргә шундый якын идем:
Очып кына мен дә... Үрел дә...
Җиде күкнең сихри бар балкышын
Мөлдерәмә тутыр күңелгә!

...Очтым... очтым хыял канатында,
Тик күкләргә җитә алмадым...
Ялгыз канат көчсез икәнлеген
Шунда гына... шунда аңладым...

Мин күкләргә шундый якын идем!.. —
Җиткән булыр идем югыйсә...
Бары да бетте... Күшек күңелемнең
Яраларын телеп җил исә...

---

* Әнвәр Бакиров көе.
** Фәүзә Гасакирова, Индус Хәбибуллин көйләр язды.

## *Тауларга менәлмәдем**

Гәүдәләрең күрмәмме, дип
Чыгам таңда юлларга.
Кара төсне сөймәс булдым,
Кайгы кара булганга.

Каралардан да карарак
Кайгының каралары.
Сине — миннән, мине — синнән
Язмышлар аралады.

Тауларга менәлмәдем,
Карадым — күрәлмәдем.
Бер гомеремә тигез итеп
Бәхетемне бүләлмәдем...

## *Үткәннәр сагындыра***

Пар аккошлар тын күлләрдә
Баласын кагындыра.
Киләчәге берни түгел,
Үткәннәр сагындыра.

Гомеремнең асыл мәле —
Үткәндә чагым гына.
Шул асыл чагым уйласам,
Үткәннәр сагындыра.

Язмышымнан күп сорамыйм,
Сорыйм бик азын гына —
Парлап үтәргә гомернең
Үткәндә чагын гына...

---

* Рәис Нәгыймов көе.
** Фоат Әбүбәкеров көе.

# *Кара әле күзләремә**

Күзләреңә, күзләреңә
Яратып карый идем.
Караган саен серлерәк
Серләрен аңлый идем.
Синдә генә, синдә генә
Яме иде дөньямның.
Нигә әле мин — синеке,
Син минеке булмадың?
Мин бит синең күзләреңдә
Күрә идем үземне.
Белмим, син артык сабырмы,
Мин артыгын түземме?
Күзләреңнән серләреңне
Мин аңлый ала идем.
Синең өчен дөрли-дөрли
Утларда яна идем.
...Йөрмик әле каңгырашып
Икебез ике якта.
Бергә булыйк, бер-беребезне
Сөеп туялмас чакта.
Кара әле күзләремә
Яратып-сөеп кенә.
Син бит минем бердәнберем,
Кадерлем, диеп кенә.

---

*Азат Хөсәенов көе.

# *Минем йөзгә ышанма син**

Минем йөзгә ышанма син,
Боек чагын күрмәссең.
Йөземә карап беркайчан
Күңелемне белмәссең.

Минем йөзгә ышанма син,
Кара булмас. Ак булыр.
Йөрәккәем мөлдер-мөлдер
Елап торган чак булыр.

Минем йөзгә ышанма син,
Кара бер күңелемә:
Ышанмасаң да йөземә,
Ышанырсың үземә!

# *Без яшәрбез...***

Күңелемне моңнар сарган, димә,
Мин үзем дә шундый хәлләрдә.
Сине искә алып җан юатам,
Өметләрем сүнгән мәлләрдә.

Җирдә яшәү нигә кирәк, димә,
Ялгызлыктан җаның киселсә,
Күзеңдәге сихри очкыннарга,
Күңелеңә сагыш бөркелсә.

Ышаныч һәм сөю яши җирдә,
Без яшәрбез алар булганда.
Тугры юлдаш булсын сезгә сөю,
Ташламасын авыр юлларда.

---

* Зәбих Мәмәлимов көе.
** Ринат Бикбулатов көе.

# *Карап калам кошлар артыннан**

Күзләр җиткән чакта
Язын безгә кайткан
Очар кошлар юлга җыена.
Өзелеп кенә көткән
Бәхетемне алар
Алып китә төсле тоела.

Карашларым уйчан,
Тезелешеп очкан
Кошларны мин юлга озаттым.
Язлар җиткәч, кабат
Очрашырбыз әле —
Үз-үземне шулай юаттым.

Тезелешеп тагын
Кошлар кайтыр язын. —
Туган җиргә юллар бер генә.
Бәхетемне юлда
Югалтмаслар микән? —
Шуны уйлап үзәк өзелә.

---

* Ганс Сәйфуллин көе.

# *Коела яфраклар*[*]

Коела яфраклар, кай ара көз килде.
Мин янам, мин дөрлим яфраклар шикелле.
Яфраклар, яфраклар биешә, күр әле.
Минем дә гомеремнең алтындай бер мәле.

Яфраклар коела ялгыз да, парлы да...
Син дә кил, сөеклем, мәңгегә калырга.
Яфраклар, яфраклар биешә, күр әле.
Синең дә гомереңнең алтындай бер мәле.

Коела яфраклар, юл түшәп карларга.
Парлашып атласак, җитәрбез язларга.
Яфраклар, яфраклар биешә, күр әле.
Безнең дә гомернең алтындай бер мәле.

Коела яфраклар...
Рәхәт тә, моңсу да...

---

* Рамил Миндияр-Камал көе.

# *Гомерләрне ашыктырма икән*[*]

Гомерләрне ашыктырма икән,—
Ул үзе дә тора үтәргә.
Тугры юлдаш сайлый белү кирәк
Тормыш юлын бергә кичәргә.
Тормыш юлын бергә кичәр өчен
Сайла ярның менә дигәнен,
Яшә аннан гомер буйларына
Күзләреннән алмый күзләрең.

Гомерләрне ашыктырма икән,—
Кадерен бел һәрбер мизгелнең.
Ике йөрәк бергә тибү кирәк,
Уты сүнмәс өчен күңелнең.
Утлары сүнмәсә күңелеңнең,
Тормыш кадере ныграк беленә.
Синең өчен мин иң кадерледер,
Минем өчен — бары син генә.

Гомерләрне ашыктырма икән,—
Үкенмәслек булсын соңарып.
Язган ярым, назлы ярым бул син,
Бәхет барсын безгә юл ярып.
Бәхет барыр безгә юллар ярып,
Икәү бер җан, бер тән булганда.
...Килгәнбез бит кунак булып кына,
Тик бер яшәү өчен дөньяга!
Тик бер яшәү өчен...

* Рөстәм Сәрвәров көе.

# *Пар канатлар (Каерма канатың)**

Пар чәчәкләр гөлдә, пар аккошлар күлдә,
Пар сандугач булса, җыр матур.
Ярыңнан аерылып, канатың каерылып
Калсаң, сине кемнәр юатыр.

Кушымта:

Җаныңны канатып, каерма канатың,—
Ташлама ярыңны, ташлама.
Синекеннән артык түгел кеше яры.
Үз канатың бирмә башкага.

Елгаларның яры һаман парлы-парлы,
Көн кояшы, төннең ае бар.
Парлыларны күреп, үзәкләрен өзеп,
Гомер итә аерым-аерылар.

Кушымта.

Бул син гел янында, кайгылы чагын да,
Шатлыгын да тигез бүлешеп.
Күзләренә карап, бер-береңне аңлап,
Гомерләр ит сөеп-сөешеп.

Кушымта.

* Илфат Дәүләтшин, Рәис Нәгыймов көйләр язды.

# *Мәңге бергә**

Бу тормышның сукмагыннан
Барган чакта икәү атлап,
Сөйгән ярың, язган ярың
Йөртсен сине һаман саклап,
Һаман саклап йөртсен сине —
Бердәнберен, кадерлесен —
Мәңгегә шул бер кешесен.

Җиңел түгел бару юлдан
Икәү бергә тигез атлап,—
Зилзиләләр көтеп тора
Борылышта сине кайчак.
Көтеп тора борылышта
Авырлык та, киртәләр дә,
Кайгысы да бу тормышта.

Ни күрсәң дә — икәү бергә,
Иңнәреңне куеп иңгә,
Туктап калма, түзалмыйм, дип,
Каршы искән усал җилгә.
Бәхетебез алда, диеп,
Атла һаман алгы көнгә,
Ни күрсәң дә — икәү бергә.
Иңнәреңне куеп иңгә,
Атла һаман ул да, син дә.
Ни күрсәң дә — икәү бергә,
Мәңге бергә, мәңге бергә!

* Габдрәзәк Мингалиев көе.

# *Сулмасыннар сөю гөлләре*[*]

Тормыш сукмагыннан барган чакта,
Син очрадың минем юлымда.
Сулмасыннар диеп,
Сулышыңны өреп,
Алсу гөлләр бирдең кулыма.

Сакладым мин назлап гөлләреңне,
Чәчәк атсын диеп тырыштым.
Янәшәмнән килеп,
Бергә сулар сибеп,
Бердәнберем, син дә булыштың.

Шаулап үсте гөлләр, чәчәк атты,
Сулмадылар җилләр тигәндә.
Һаман бергә-бергә,
Гөлләр кебек без дә
Гөрләп яшик алгы көннәрдә.

---

* Азат Хөсәенов көе.

# *Гомерләр үтмәгән**

Чәчәкләр сула дип, гомерләр уза дип,
Күз килде җиргә дип моңланма.
Кадерләрен белеп алтындай гомернең
Син яшәп калырга соңлама.
Гомерләр үтмәгән, күз әле җитмәгән,
Елыйбыз, көләбез — яшибез бит әле.

Без китте дип җирдән, тукталмас гомерләр,
Яшәрләр, сөярләр безнеңчә.
Карамый кешегә, иртәсе-киченә,
Син яшә бу җирдә үзеңчә.
Гомерләр үтмәгән, күз әле җитмәгән,
Сөябез, янабыз — яшибез бит әле.

Килгәнбез бу җиргә мәңгегә түгел лә,
Йолдыздай бер балкып сүнәргә.
Изге эш-гамәлләр кылсак без әгәр дә,
Калырбыз сагынып сөйләргә.
Гомерләр үтмәгән, күз әле җитмәгән,
Йолдыздай балкыйбыз — яшибез бит әле.
Сөябез, янабыз — яшибез бит әле.

* Азат Хөсәенов көе.

# *Җирсу**

Сагыну-сагышларга чара табалмыйча,
Авылыма кайткан чагында,
Үзәкләрне өзеп яңара яңадан
Мәтрүшкәләр исе җанымда.

Балачагым калган эзләрне эзләргә
Урләренә йөгереп менгәндә,
Бәбкәләре белән казлар йөри һаман,
Атлар кешнәп кала үзәндә.

Кай якларга китеп гомер итсәм дә мин,
Кем генә булсам да, кайчан да,
Газиз туган халкым, әткәм-әнкәм хакы
Авылыма дәшеп кайтара.

---

* Альберт Шакиров, Фәрит Хатыйпов көйләр язды.

# V

*...Сөйләштек тә, серләштек тә, дуслар,*
*Әйтер сүзләр тагын калды әле...*

* * *

Дөнья безне тик бер генә түгел,
Әллә ничә инде сынаган.
Шуңадыр да юлның киртәләрсез,
Шоп-шомасын сайлап куймаган.

Көчлелекне безнең белгәнгәдер,
Өеп сала иңгә авырлык.
Сыгылмыйбыз, сынмыйбыз без һаман,
Көч табабыз алга барырлык.

Кайгы бирә, хәсрәтләрне бирә,
Мескен иңнәр генә күтәрсен!
Туктап калып, утырып бер уйласаң,
Уйларыңнан уелып китәрсең!

Туктамыйча, уйланмыйча гына
Һаман алга, алга барган көн!
...Дөнья үзе беркөн бәреп егар —
Без туктарбыз әле аннан соң!

* * *

Маңгаема сырлар ятты,
Чәчләремә чаллар инде...
Ләкин күпме яшәсәм дә,
Аңламадым, гомер, сине.

Йөгереп кенә яшьлек үтте,
Аксап-туксап картлык җитте.
Мин аларга һаман әле
Читтән карап торам төсле.

Китәрмендер. Бер мин генә
Артыграк тормам инде...
Ничә тапкыр яшәсәм дә,
Аңламамын, гомер, сине...

* * *

Кемнәр белә: бәлкем, минем гомер
Сезгә озак кебек тоелыр...
Тупаслыкка бәрелеп,
Әрле-бирле сугылып йөрер дә ул,
Булмаган да кебек җуелыр.

Сизмәсләр дә минем юк икәнне,—
Барлыгымны белмәгән кебек...
Кемдер юксынганда,
Икенчеләр, азмы андыйлар, дип,
Авыз ерып торырлар көлеп.

Кемдер сорар: «Кем иде ул?— диеп.—
Ят кешеме. Бер-бер танышмы?»
Мин әйтермен:
— Мин идем ул...— диеп,—
Сугылып чыккан идем сезнең янга,
Дөнья буйлап үтеп барышлый...

* * *

Алмагачлар ап-ак күлмәк кигән,
Шау чәчәктә әнә бар гөлләр.
Безнең дә бит, шул язгы гөлләрдәй,
Ап-ак күлмәк кияр мизгелләр.

Җан аклыгы чагыла күзләрдә,
Күңел канат җилпи хыялга.
Хыялны чын итәр дусларым бар,
Мин ышанам бүген шуларга.

Сихри дөнья һаман алга дәшә,
Бер күкрәп, бер килә яшьнисе.
Кадерләрен белеп гомерләрнең
Яшисе дә әле яшисе.

# *Эчтәлек*

Кояш нуры тамган җырлар. *Әхмәт Рәшит* . . . . . . 3

**I**

Ышанам. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Бәхетең үз кулыңда. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
«Күзенә карыйм да...». . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Яшәүнең үзеннән көч алам. . . . . . . . . . . . . . 11
«Мөкәлләф булганыма бән...» . . . . . . . . . . . . 12
«Яз иде бит әле...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
«Яфрак коя-коя, моңсу гына...». . . . . . . . . . . 14
«Тормышта мин юллар салып барам...». . . . . . . 14
«Кояш көткән чакта яңгыр ява...» . . . . . . . . . 15
«Зиратларга керсәм, хәйран калып...». . . . . . . 16
Үкенмәмен. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
«Ел фасылы алмашынган саен...». . . . . . . . . . 18
«Тәрәзәдән карап утырам мин...». . . . . . . . . . 18
«Җиргә язлар килә...». . . . . . . . . . . . . . . . . 19
«Көзге җилдә өем-өем...». . . . . . . . . . . . . . . 20
Көзге этюд. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Бар табигать инде көзгә кергән...». . . . . . . . 22
«Һәр фасылы газиз, дибез дә бит...». . . . . . . . 23
«Чиста җаным белән аваз салам...». . . . . . . . . 24
«Ак каенда аклык, сафлык төсе...». . . . . . . . . 24
Шулай, димәк. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
«Кайда куйсаң, шунда кыйммәт...». . . . . . . . . 26
«Кырык тугыз әле илле түгел...». . . . . . . . . . . 27
Ходайга ялварам иң элек. . . . . . . . . . . . . . . 27
Кем ничек. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
«Кич саен юатам үземне...». . . . . . . . . . . . . . 29
«Тупас җаннар бәрелеп күңелемә...». . . . . . . . 29
«Әнкәй, бәгърем, ни дип яраттың мине бу тормышка...» 30
«Бер кешегә юк эчемдә каралык...». . . . . . . . . 30
«Бөгелмәм, дидем. Бөгелдем...». . . . . . . . . . . 31
«Нәрсә булды әле?..». . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
«Бар табигать суга тилмергәндә...». . . . . . . . . 33
«Моңа кадәр белмәгәнмен генә...». . . . . . . . . 34
«Сикереп кенә атланыр да идең...». . . . . . . . . 34
«Бәгыремә тиде салкын...». . . . . . . . . . . . . . 35
Хәлемне сорамагыз. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
«Җилфер-җилфер генә искән җилләр...». . . . . . 37
«Нигә күңелләрең боек...». . . . . . . . . . . . . . 37
«Дөньям житеп ашкан кебек минем...». . . . . . . 38
Әгәр үлә калсам... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
«Сипмә лә, язмыш, тозыңны учлап...». . . . . . . 39

«Гомерем буе йокыдан...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
«Мөэмин рамазан ае бүген...» . . . . . . . . . . . . . . . 41
«Бала чактан күптән киттем инде...» . . . . . . . . . . 42
Минем әнкәй дә картайган инде... . . . . . . . . . . . 42
«Әнкәй, бәгърем, беләм, синең чәчләр...» . . . . . . . 43
«Үдебедчә, «кыдыл бодау»ларча...» . . . . . . . . . . 44
«Рәнҗемә миңа, инәкәем...» . . . . . . . . . . . . . . . 45
«Мин дәвамы булып яралганмын...» . . . . . . . . . . 45
Улым белән кызыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Кызыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
«Кызым минем!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Уйна, кызым! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
«Балаларым! Ике канатым сез...» . . . . . . . . . . . . 49
«Без бу җирдә бары Мөслимнеке!..» . . . . . . . . . . 50
«Мөслимемә кайтасым бар әле...» . . . . . . . . . . . 50
«Әй, ак болыт, кая синең юлың?..» . . . . . . . . . . 51
«Сабантуйлар җитте, сабантуйлар!..» . . . . . . . . . 52
«Мөслимемдә тагын сабан туе!..» . . . . . . . . . . . 53
Мөслимдә сабантуйда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
«Әнисен күрүдән өмет өзеп...» . . . . . . . . . . . . . 54
«Йөрим төнге Мөслим урамында...» . . . . . . . . . . 55
«Мөслимемә тагын кайттым әле...» . . . . . . . . . . 56
«Очып барам самолетта Мөслимемә...» . . . . . . . . 57
«Мөслимдә төн, ай-һай, кыска икән...» . . . . . . . . 57
«Әй, садә җил, канатланып кил дә...» . . . . . . . . . 58
«Үз туфрагында туып үскән егет...» . . . . . . . . . . 59
Казан — Мөслим юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59

## II

Тимәгез сез миңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
«Кемдер ансат кына...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
«Йа Ходаем, нинди замана бу?!» . . . . . . . . . . . . 64
«Бик сәер заманда...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
«Мине гомерем буе орышалар...» . . . . . . . . . . . . 65
«Бер генә дә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
«Газиз туган телем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Кайтма, Тукай! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
«Кемдер әйтер...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
«Дуслар» димсез?!» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Кырыкныкы — шырыкта... . . . . . . . . . . . . . . . 71
Ышанма син кешеләргә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
«Нәрсә күрдем соң мин...» . . . . . . . . . . . . . . . . 74
«Мин яраттым сине...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
«Синсез генә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
«Кияүгә чык, дисең...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
«Юлда туңып, хәлдән таеп...» . . . . . . . . . . . . . 77
Килгән идем җиргә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78

«Минем бу дөньяда барлыгымны...». . . . . . . . . . . . 79
«Син кемнеңдер иркә кочагында...». . . . . . . . . . . . 80
«Басып торам очлы тау башында...». . . . . . . . . . . . 80
«Иртән торам...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Балаларыма васыять урынына. . . . . . . . . . . . . . . 82
«Сөям» дә «сөймим» диеп...». . . . . . . . . . . . . . . 83
«Аерылышкач...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
«Йөгергән булдым гел алга...». . . . . . . . . . . . . . 84
«Урманнарда йөрдем берьялгызым...». . . . . . . . . . . 85
«Кара инде бу дөньяны...». . . . . . . . . . . . . . . . 86

## III

«Аңладым, дип, бу дөньяны...». . . . . . . . . . . . . 88
«Тәрәзәдән карап утырам мин...». . . . . . . . . . . . . 88
«Язларында ялгыз йөрсәң...». . . . . . . . . . . . . . . 89
«Минем гомер гел челләдән торды...». . . . . . . . . . . 90
«Сыздырып ла гармун уйнап узды...». . . . . . . . . . . 91
«Аһ, дисәм дә, уһ, дисәм дә...». . . . . . . . . . . . . 91
«Көндез кояш кирәк булса...». . . . . . . . . . . . . . 92
«Гомер буе җыйган серләремне...». . . . . . . . . . . . 93
«Бүген таңда мине сискәндереп...». . . . . . . . . . . . 93
«Син йоклыйсың, бәгырькәем, изрәп...». . . . . . . . . 94
«Моңа кадәр әллә чын сөюнең...». . . . . . . . . . . . 94
Минем өчен бары шул җиткән... . . . . . . . . . . . . . 95
«Эшең күп шул...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Үкенмә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
«Үткән сөю, узган хәлләреңне...». . . . . . . . . . . . 97
«Иренемдә иренеңнең тәме...». . . . . . . . . . . . . . 97
«Мин сиңа нәрсәгә? — дисең син...». . . . . . . . . . . 98
«Битәрләмә, җаныем, үз-үзеңне...». . . . . . . . . . . . 99
«Авызларыңа каратып...». . . . . . . . . . . . . . . . 100
«Синең белән бергә яшәү...». . . . . . . . . . . . . . . 100
«Менә инде бер көн синсез яшим...». . . . . . . . . . . 101
«Язгы аяз күктә төсмерләнә...». . . . . . . . . . . . . 102
«Көнемнең ничә сәгате...». . . . . . . . . . . . . . . . 102
«Белгән кебек кайдан килдең...». . . . . . . . . . . . . 103
«Шулайдыр...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
«Мин аңлыйм...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
«Ашыктырма». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
«Мәңге тынмас сагышым син...». . . . . . . . . . . . . 105
«Яратма син, дисең, мине алай...». . . . . . . . . . . . 106
«Борчуларың, әйдә, үземә бир...». . . . . . . . . . . . 107
«Күзләреңне үбеп, иренемә...». . . . . . . . . . . . . . 107
«Сагынуларга түзми, күзләреңнән...». . . . . . . . . . . 108
«Мине сагынудан синең дә...». . . . . . . . . . . . . . 108
«И җанашым, җаным ла...». . . . . . . . . . . . . . . . 109
«Бар исемнәр арасында...». . . . . . . . . . . . . . . . 109

«Теләмәсәң...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Димәс идем. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
«Саубуллашмый гына китеп бардың...». . . . . . . . . 112
«Килми инде сине сагынасым...». . . . . . . . . . . . 112
«Ташлама»,— дисәм дә...». . . . . . . . . . . . . . . 113
«Оныттым» диеп уйлама...». . . . . . . . . . . . . . 114
«Бәхеттән әйләнсә башларың...». . . . . . . . . . . . 114
«Юатмачы, язлар килер, диеп...». . . . . . . . . . . . 115
Китә алсаң, үзең кит миннән. . . . . . . . . . . . . . 116
«Әзме-күпме тәҗрибәм бар хәзер...». . . . . . . . . . 117
«Ничек түзәсең син сагынмыйча...». . . . . . . . . . . 118
«Син инде «үлгән» идең...». . . . . . . . . . . . . . . 119
«Чәчләрем озын чагында...». . . . . . . . . . . . . . 120
Кем белә?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
«Каршы чыктым юлларыңа...». . . . . . . . . . . . . . 121
Килә күрмә түгел... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
«Сулышыңның һәр чемкелен тоям...». . . . . . . . . . 122
«Әгәр минем хакта сорасалар...». . . . . . . . . . . . 123
«Чыгыйк та без япан кырларга...». . . . . . . . . . . 123
«Мин сине сөйгән идем...». . . . . . . . . . . . . . . 124
«Син упкынның кырыенда инде...». . . . . . . . . . . 124
«Миңа күптәннән аңларга вакыт...». . . . . . . . . . 125
«Хәтәр сүздән, хәнҗәр сүздән...». . . . . . . . . . . 126
«Бүген көчле яңгыр булыр, ахры...». . . . . . . . . . 126
«Рәнҗеп калма...». . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
«...Төшләремдә күрү беләнмени?!». . . . . . . . . . . 128
«Төн сәгате күптән суккан инде...». . . . . . . . . . . 128
«Безгә нәрсә?! Без күнеккән инде...». . . . . . . . . . 129

**IV**

Хәерлегә булсын. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Хәтер җыры. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Торналар кычкырып уздылар. . . . . . . . . . . . . . 134
Мәңге яшә, Татарстаным! . . . . . . . . . . . . . . . 135
Татарстаным минем. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Без мәңге синеке, Казан! . . . . . . . . . . . . . . . 137
Минем кадерлеләрем. . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Изге теләк. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Сагынам сине, әнием. . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Әткәем. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Туган якка кайтып киләм әле. . . . . . . . . . . . . 142
Туган-үскән якларым. . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Мөслимем. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Туган көнең белән! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Әйдә, биик! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Ач күзеңне — дөнья бу! . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Хуш килдең, Яңа ел! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

Язлар да җитә инде. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Яңгыр ява, яңгыр ява. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Кайда сез, ирләр?. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Исемнәрең дөрес куелган. . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Лилия. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Иделкәем. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Байкал күлләренә бардым. . . . . . . . . . . . . . . . 155
Сезнең якка юллар сорыйсы юк. . . . . . . . . . . . . 155
Сабыр ит син, димәгез... . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Язган ярым түгел, калган ярым. . . . . . . . . . . . . 157
Нишлим. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Бураннар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Ак күлмәгем. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Ни өчендер безнең язмыш шундый. . . . . . . . . . . . 160
Ярат мине. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Көнгә биш кенә минут. . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Сау бул инде. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Әмер. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Исеңә төшәр әле. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Мин яратам, ә син юк әле. . . . . . . . . . . . . . . . 165
Мин идем ул. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Үзең килгәч күрерсең. . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Өзелеп сөйгәнгә күрәдер. . . . . . . . . . . . . . . . 168
Ышан миңа. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Үпкәләмә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Исемеңне саклыйм йөрәгемдә. . . . . . . . . . . . . . 170
Син мине күрмәдең. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Мин күкләргә шундый якын идем. . . . . . . . . . . . 171
Тауларга менәлмәдем. . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Үткәннәр сагындыра. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Кара әле күзләремә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Минем йөзгә ышанма син. . . . . . . . . . . . . . . . 174
Без яшәрбез... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Карап калам кошлар артыннан. . . . . . . . . . . . . 175
Коела яфраклар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Гомерләрне ашыктырма икән. . . . . . . . . . . . . . 177
Пар канатлар (Каерма канатың). . . . . . . . . . . . 178
Мәңге бергә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Сулмасыннар сөю гөлләре. . . . . . . . . . . . . . . . 180
Гомерләр үтмәгән. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Җирсү. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182

## V

«Дөнья безне тик бер генә түгел...». . . . . . . . . . . 184
«Маңгаема сырлар ятты...». . . . . . . . . . . . . . . 185
«Кемнәр белә: бәлкем, минем гомер...». . . . . . . . . 185
«Алмагачлар ап-ак күлмәк кигән...». . . . . . . . . . . 186

Литературно-художественное издание

*Шамсия Зигангирова*
*(Зигангирова Шамсия Гатуфовна)*

# *Ностальгия*

Стихи, песни

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Й.М.Вәлиәхмәтов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 0201 нче номерлы лицензия
1997 елның 22 августында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 12.01.2001. Форматы $70 \times 90^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Антиква» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 7,02+ф.0,5. Шартлы буяу-оттиск 7,9. Нәшер-хисап табагы 6,43+ф.0,26. Тиражы 3000. Заказ А-6.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Татарстан газета-журнал нәшрияты» Дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.